ЯКШӘМБЕ
29
ДЕКАБРЬ
1940 ел.
№ 302 (6102)
Аерым номеры 10 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ,
ШӘҺӘР КОМИТЕТЫ,
ТАССР ВЕРХОВНЫЙ
СОВЕТЫ ҺӘМ ШӘҺӘР
СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

Кышкы агрономия чаралары планын тулысынча үтәргә

Быел Татарстанда иген уңышы үткән елдагыга чагыштырганда югарырак булды. Ләкин, турыдан-туры әйтергә кирәк, Татарстанның күп кенә колхозларындагы һәм совхозларындагы иген уңышы өченче бишьеллык план буенча алга куелган бурычка, өченче бишьеллык ахрына ел саен 8 миллиард пот ашлык җитештерүгә ирешү бурычына җавап бирүдән ерак тора әле. Бездә әле бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача бары 7-8 центнер гына иген уңышы алып килүче колхозлар, кызганычка каршы, байтак исәпләнәләр.

ВКП(б) ның тарихи XVIII нче съездында ясаган докладында иптәш Сталин:

«... Безнең игенчелегебез иң эре һәм механикалаштырылган игенчелек кенә түгел, һәм димәк, иң товарлыклы игенчелек кенә түгел, бәлки башка кайсы илнең генә игенчелегенә караганда да хәзерге заман техникасы белән ныграк коралланган игенчелек», диде.

Димәк, бездә югары иген уңышы алу өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Тик алардан оста итеп файдаланырга гына кирәк, механизмнарны төгәл эшләтү белән бергә, алдынгы—совет агрономиясе казанышларын, агротехника чаралары комплексын тулысынча тормышка ашырырга гына кирәк. Быел күп кенә колхозларның, бригадаларның һәм звеноларның бик яхшы иген уңышы алуларының төп сере дә, барыннан да элек, әнә шунда—агрономия чаралары комплексын тулысынча үтәүләрендә.

Менә берничә факт. Кызыл Армия районы, «Марс» колхозының иптәш Асматов звеносы быел 40 гектар мәйданда бодайның һәр гектарыннан уртача 17 центнер, 3 гектар мәйданда һәр гектардан уртача 25,5 центнер уңыш алды. Ә шул ук культура буенча «Марс» колхозындагы уртача уңыш бары 6,43 центнер гына булды. Аксубай районының «Коминтерн» колхозы звеноводы иптәш Вадышеваның да бодай буенча алган уңышы колхоздагы уртача уңыштан ике тапкыр артыграк. Иптәш Вадышеваның бер гектар бодае 33 центнер уңыш бирде. Чөнки иптәш Вадышева да һәм иптәш Асматов та агрономия чаралары комплексын тулысынча үткәрделәр: туфракны тирән итеп, иртә срокларда көздән туңга сөреп калдырдылар, кыш көне 1—1,5 метр калынлыкта кар тоттылар, яз көне кар суларын тотып калу чараларын үткәрделәр, иң кыска срокта чәчтеләр, иң яхшы орлык кына чәчтеләр, җирле ашламалар белән тукландырдылар, чүп үләннәрен җентекләп утадылар һәм, ниһаять, бер бөртеген дә югалтмыйча урып җыйдылар. Ә гомумән алганда, «Марс» колхозында да һәм «Коминтерн» колхозында да күп участкыларда югарыда күрсәтелгән чараларның кайберләрен генә үткәрү белән чикләнделәр. Шуңа күрә бу колхозлардагы иген уңышы Асматов һәм Вадышева звеноларындагыдан күп түбән булды.

Чыннан да, бездә әле күп кенә колхозларда һәм кайбер районнарда агрономия чараларын, бигрәк тә кышкы агрономия чараларын (кар тоту, ашлама хәзерләү, басуга тирес чыгару, орлык хәзерләү һ. б.) үткәрүгә җитәрлек игтибар бирелми. Агрономия чаралары комплексында иң әһәмиятле булып исәпләнгән кар тоту, җирле ашламалар туплау һәм алардан дөрес файдалану планнары республикабызда ел саен дип әйтерлек тулысы белән үтәлми кала.

Кышкы агрономия чараларына карата былтыр ел булган кимчелекләр быел да кабатлану фактлары бар. Мәсәлән, Чистай районында (район җир бүлеге мөдире иптәш Гришин) 73 колхозның 31 енде бүгенге көнгә дә әле кар тоту чараларын үткәрергә керешмәгәннәр. Кузнечиха районының «Яңа Тормыш» колхозында басуга чыгарып, анда бер-монда бер чыбык ташлыйлар да «кар тоттык» дип исәплиләр. Тельман районында (район җир бүлеге мөдире иптәш Тукманов) кар тоту планы бары 25 процентка үтәлгән. Басуга тирес чыгаруда да һәм җирле ашламаларны туплауда да шундый ук зур кимчелекләр бар. Яңа Чишмә районының Чкалов исемендәге колхозында һәм Кызыл Армия районының «XVII нче партсъезд» колхозында тиресне басуга чыгарып ничек туры килсә һәм кайда туры килсә шунда түгәләр дә, «басуга тирес чыгардык» дип исәплиләр. Тирес чыгарыла торган участкыда алдагы елда нинди культура чәчеләчәген, ул участкының нинди ашламага мохтаҗ булу-булмавын бөтенләй исәпкә алмыйлар.

Минераль ашламалардан файдалану буенча да шундый ук зур, һич тә гафу ителмәслек кимчелекләр яши. Тимер юл станцияләренә кайтарылып та колхозларга үз вактында ташылмыйча яткырылу, яки колхозга кайтарылгач та дөрес сакланмау нәтиҗәсендә минераль ашламаларның бозылу фактлары күп кенә колхозларда ел саен кабатланып килә.

Билгеле, иң әһәмиятле агрономия чараларын да әнә шулай үткәргәч, андый колхозлар югары иген уңышы өчен чынлап көрәшәләр, дип кем әйтә алыр инде? Һич кем!

Татарстан АССР дагы туфракларның дымга да һәм шулай ук һәр төрле ашламаларга да аеруча мохтаҗ булуларын истән чыгарырга ярамый. Ә бу мохтаҗлыкны каплау өчен хәзергә кадәр бик аз файдаланылган чиксез күп материал резервлар бар. Тирес тә, торф та, известь тә һәм кыйммәтле башка төр җирле ашламалар запасы да бездә бар. Аларны һич тә әрәм итмичә җыярга һәм дөрес итеп файдалануны оештырырга кирәк. Хәзергә кадәр колхозларыбызның үтә күпчелегендә тирес саклау, тирес сыекчасы җыю урыннары булмауны иң зур кимчелекләрнең берсе итеп исәпләргә кирәк. Ә бит тирес, әйтик, кыш көне дөрес сакланмаса, яз көне туфракка керткәнчегә кадәр үк үзендәге туклыклы матдәләрнең 50 процентын югалта. Һәрбер колхозда һәм һәрбер совхозда кышкы агрономия чаралары планнары һич сүзсез тулысынча һәм яхшы сыйфатлы итеп үтәлергә тиеш. Бу эшкә Татнаркомзем, район җир бүлекләре һәм агрономнар җитәкчелеген тәэмин итәргә кирәк. Ә мондый җитәкчелек кызганычка каршы, Татнаркомзем тарафыннан да һәм күп кенә район җир бүлекләре тарафыннан да һаман да әле канәгатьләнерлек түгел. Татнаркомземның производство-территориаль управлениеләре бигрәк тә эшлексезлек күрсәтәләр. Управлениеләрнең берсе дә дип әйтерлек кышкы агрономия чараларының үтәлеше буенча районнардагы һәм колхозлардагы чынбарлыкны белмиләр. Бу яраксыз практиканы, искечә эшләүне ташларга кирәк. Югары иген уңышы үзеннән-үзе килми, аны зур тырышлык белән генә яулап алырга мөмкин. Моны хәтердән чыгарырга ярамый.

Татарстан АССР колхозларында һәм совхозларында 1941 нче елгы агрономия чаралары һәм ашламалардан файдалану турында газетабызда Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросының бүген игълан ителгән карары, һәрбер район, совхоз һәм колхоз өчен конкрет эш программасы булып тора. Бу карарны һәрбер районда, совхозда һәм колхозда тиз арада тормышка ашыруны кичекмәстән җиткерергә кирәк.

Кышкы агрономия чаралары планнарын, барлык төр ашламалар туплау планын һәм алардан файдалану планнарын үтәү өчен социалистик ярышны киң җәелдерергә кирәк!

Колхозчылар ярышы

АПАС, 28 декабрь. (ТатТАСС). Апас районы колхозчылары партиянең XVIII нче Бөтенсоюз конференциясе хөрмәтенә социалистик ярышны көннән-көн киң җәелдерәләр. «Правда», «25 Октября», «Нариман» исемендәге, Энгельс исемендәге колхозлар ... Хөсәен Ямашев исемендәге колхозда (бөтенесе 17 колхозчы) чәчүлек орлыкларны тазарту тәмамланды.

Х. Ямашев исемендәге колхозда кар тоту һәм кырга тирес чыгару эшләре уңышлы бара. 368 гектар мәйданда кар тоту үткәрелде инде. Колхозчы хатын-кызлардан Б. Зиннәтуллина һәм Н. Шәйхеттинова иптәшләр бу эштә гүзәл үрнәкләр күрсәтәләр. Алар көнлек эш нормаларын 150 процентка арттырып үтиләр.

«25 Октября» колхозында 277 гектар мәйданда кар тотылды, кырга 2.000 нән артык центлар чыгарылды. «Комбайн» колхозы членнары ВКП(б) ның XVIII нче Бөтенсоюз Конференциясе хөрмәтенә язгы чәчүгә хәзерлек эшләрен тиз арада тулысынча тәмамлау йөкләмәсен кабул иттеләр һәм «Тырыш» колхозын социалистик ярышка чакырдылар.

Казандагы мальтоз-патка эшләп чыгара торган «Пламя» заводы коллективы заводның еллык производство программасын 9 нчы декабрьдә үтәде. Рәсемдә: лаборатория стахановчысы иптәш В. М. Плишкова мальтозның куелыгын тикшерә. В. Лаврентьев фотосы.

Партиянең XVIII нче Бөтенсоюз конференциясе хөрмәтенә

ГҮЗӘЛ КҮРСӘТКЕЧЛӘР

Серго Орджоникидзе исемендәге завод цехларында ВКП(б) ның XVIII нче Бөтенсоюз Конференциясе хөрмәтенә оештырылган социалистик ярыш көннән-көн киң колач ала.

ВКП(б) ның XVIII нче Бөтенсоюз Конференциясе хөрмәтенә булган вахталарга басучы кешеләр сафы туктаусыз үсә. Клепальщик иптәш Нәгыймов Баһау тәҗрибәсе заводның башка цехларына һәм мастерскойларына да күчерелә. Билгеле булганча, иптәш Алешин җитәкчелек иткән цехта эшләүче иптәш Нәгыймов 25 нче декабрьдә көнлек заданиесен 1.160 процентка үтәп, бу көнне 298 сум хезмәт хакы алу рекордын биргән иде. Иптәш Нәгыймов методы белән эшләүче слесарь иптәш Вашарин 26 нчы декабрьдә смена заданиесен 900 процентка, клепальщик Ибраһимов һәм Кошкин иптәшләр 27 нче декабрьдә нормаларын 650 шәр процентка үтәделәр.

Хезмәт җитештерүчәнлегенең югары күрсәткечләрен бирүче стахановчылар сафы туктаусыз үсә. Мәсәлән, фрезеровщик иптәш Николаев 28 нче декабрьдә смена заданиесен 875 процент итеп үтәде. Һәм бу сменада ул 116 сум 25 тиен хезмәт хакы эшләде. Токарь иптәш Трухов нормасын 521 процент, иптәш Абдрахманов 603 процент итеп үтәделәр. Установщик иптәш Шакиров 25 һәм 45 минут таләп иткән детальләрне бер минут эчендә башкара. Күп станокчы комсомолец иптәш Галиуллин элек 3—4 автомат-станокларына хезмәт күрсәткән булса, хәзер ул 10 станокка хезмәт күрсәтә.

Завод җитәкчеләре стахановчыларның бу рекордларын массовый итү өчен практик чаралар күрәләр. Монда завод директорының зур булышлык күрсәтүен аеруча билгеләп үтәргә кирәк.

Б. Корбанов.

ТИМЕР ЮЛЧЫЛАР ЯРЫШЫ

Партиябезнең XVIII нче Бөтенсоюз Конференциясен чакыру турында ВКП(б) Үзәк Комитеты карары Казан тимер юлчылары тарафыннан политик һәм производство активлыгының яңа һәм тагын да көчлерәк күтәрелеше белән каршыланды. Тарихи конференция хөрмәтенә оештырылган социалистик ярышка тимер юлчылар зур бердәмлек белән кушылдылар. Бу уңай белән хәзер элекке ярыш договорлары яңартыла. Бүлек белән бүлек, узел белән узел, станция белән станция коллективлары үзара ярыш договорлары төзеп, конкрет йөкләмәләр алалар.

Мәсәлән, Казан узелы Муром узелы белән, Казан станциясе Муром станциясе белән ярышка чыкты. Бу ярышта казанлылар 1941 нче елның 1 нче квартал планын 15 көн алдан үтәү, йөк төяү һәм бушату буенча көнлек норманы 110—120 процент итеп үтәү йөкләмәсен алдылар. Ә паровозчылар коллективы исә үз паровозларында техник тизлелек нормасын 15 процентка арттырып үтәүне һәм ягулыкка иң кимендә 10 процент экономия ясауны ышандырдылар.

Ярышның беренче көн нәтиҗәләре алган йөкләмәләрнең яхшы үтәлүе турында сөйлиләр. Мәсәлән, соңгы вакытларда Казан станциясе коллективы көнлек йөк төяү һәм бушату планын 115—120 процентка үти башлады. Машинистлардан Атабегов, Волжанин, Иванов, Динмөхәмәтов, Логинов һәм башка иптәшләр үз паровозларын зур тизлек белән йөртәләр, норма үтәлешен 120—130 проценттан киметмиләр.

1941 нче хуҗалык елын Казан узелы коллективы гомумән үз эшендә яхшы гына күрсәткечләр белән каршылый. Эшнең хәлиткеч тармагы булган йөк төяү һәм шулай ук бушату планы беренче декабрьдә үк, ә декабрь ае планы 15 көндә үтәлде. Кышкы шартларда эшләүгә хәзерлектә паровозлар, вагоннар һәм юллар хуҗалыгы тулы тәртипкә кителде. Шуның нәтиҗәсендә Казан узелы хәзер тоткарсыз һәм авариясез эшли. Паровозлар паркы үзенең йөреш нормасын арттырып үтәү белән бергә, 11,5 ай эчендә 320 тонна таш күмергә экономия ясауга да ирешті.

— Тарихи конференция хөрмәтенә оештырылган социалистик ярыш безнең бу уңышларыбызны тагын да кабатлар. Бу ярышта җиңеп чыгу өчен, өстебезгә алган йөкләмәләрне тулы үтәү өчен барлык чараларны күрәчәкбез,— ди Казан узелының партбюро секретаре иптәш Ерин.

ЗАВОД КҮТӘРЕЛЕШТӘ

С. М. Киров исемендәге 4 нче номерлы ясалма каучук заводы эшчеләре һәм инженер-техник работниклары ВКП(б) ның XVIII нче Бөтенсоюз Конференциясе хөрмәтенә оештырылган социалистик ярыш йөкләмәләрен намус белән үтиләр. Соңгы көннәрдә завод коллективы үзенең эшен аеруча яхшыртты.

Мәсәлән, 25 нче декабрьдә көндәлек план завод буенча 119,9 процент, ә рафинированный каучук җитештерү буенча 118 процент итеп үтәлде.

Начальнигы иптәш Усманов булган обработкалар цехы алдынгылар сафына чыкты. Моңа кадәр арттa калып килгән бу цех коллективы 26 нчы декабрьдә үзенең көнлек нормасын 118,3 процентка, ә рафинированный каучук эшләү планын 129 процентка үтәде. Стахановчылардан Тарлецкий, Соколов, Галиев, Мальков, Гыйлметтинов, Зарипов, Фатыйхов, Шакиров һәм башка иптәшләр көнлек норма үтәлешен 200—300 проценттан киметмиләр.

Начальнигы иптәш Стрельников булган цех коллективы да ярышта алган йөкләмәләрен үтәүдә алдынгылардан калышмый. Ул үзенең производство планын сан һәм сыйфат ягыннан да арттырып үти. Стахановчы-слесарь Шәфигуллин, берьюлы 24 шәр аппаратта эшләүче Иванова, Якушева, Дәминова һәм башка иптәшләр хезмәт җитештерүчәнлегенең аеруча үрнәк күрсәткечләрен бирәләр.

И. Ногманов.

ЯҢА ЧИШМӘ ҺӘМ МИНЗӘЛӘ САЙЛАУ ОКРУГЛАРЫНДА САЙЛАУ КАМПАНИЯСЕ

Хәзерлек зур оешканлык белән бара

КРАСНЫЙ БОР, 27 декабрь. (Телефон буенча). Районда сайлауларга хәзерлек эшләре киң җәелдерелде. Сайлау участкыларының чикләре билгеләнде. Барлыгы 32 сайлау участкысы төзелде. Комиссияләрнең составында районның иң алдынгы кешеләреннән Татарстан АССР Верховный Советы депутаты Хәйруллина, район советы депутатларыннан Гумерова, Минһаҗова, Сафин, Глухова, Вахламов, Хуҗина, Нуриев, Ишпаев һәм Шустова иптәшләр бар.

Сайлауларга хәзерлек буенча агитация-масса эшләре көчәя. Агитаторлар аерым участкыларга беркетелделәр. Районда барлыгы 477 агитатор эшли. Аларның иң күпчелеге үткән сайлауларда эшләп тәҗрибә алган кешеләр. Сайлауларны үткәрергә билгеләнгән биналар җиһазландырылды. Сайлаучыларның исемлекләрен төзү тәмам булып килә.

30 нчы декабрьдә уку өйләре мөдирләренең район күләмендә киңәшмәсе үткәрелә. Сайлау алды җыелышларына иң алдынгы кешеләрне вәкил итеп җибәрү өчен аңлату эше алып барыла. 4 нче январьда ВКП(б) райкомы бюросында сайлауларга хәзерлек буенча ике авыл партоешмасының докладлары тыңланачак. Райком секретаре иптәш Ибатуллин сайлауларга хәзерлек турында радио буенча доклад ясады.

М. Әминев.

Агитпунктлар эштә

ӘГЕРҖЕ, 27 декабрь. (Телефон буенча). Минзәлә сайлау округыннан Милләтләр Советына депутат сайлау буенча Әгерҗе районында агитация-масса эшләре көннән-көн җәелә. Районда 18 агитпункт төзелде. Агитпунктларда 300 дән артык агитатор эшли. Авылларда һәр 10 йортка бер агитатор беркетелде. Алар СССР Конституциясе һәм сайлаулар турындагы Положение турында беседалар үткәрәләр. Күп кенә агитпунктлар, шул исәптән Иҗбуби, Иҗбайки, Сарсак Омга һәм Тирсә авылларындагы агитпунктлар үзләренең эшләрен бик яхшы итеп башлап җибәрделәр.

Сайлауларга хәзерлек буенча күп кенә оештыру эшләре үткәрелде. Сайлауларга хәзерлек уңае белән авыл советы башкарма комитетлары председательләре һәм агитаторлар белән берлектә инструктив киңәшмәләр үткәрелде. Сайлау участкыларында һәм агитпунктларда җаваплы дежурныйлар эшлиләр.

Салих Миңнегалиев.
ВКП(б)ның Әгерҗе райкомы секретаре.

Район советы сессиясендә

МИНЗӘЛӘ. (Үз хәбәрчебездән, телефон буенча). 25 нче декабрьдә Минзәлә район советының 7 нче сессиясе булып үтте. Сессиядә „Марс", „Сталь" һәм Димитров исемендәге колхозларда ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы карарының үтәлеше турында колхоз председательләренең докладлары тыңланды. „Марс" колхозы (председателе иптәш Сафин), авыл советы башкарма комитеты белән берлектә, ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумының карарын үтәү буенча зур гына эшләр башкарган. 1941 нче елгы язгы чәчү өчен җитәрлек күләмдә чәчүлек орлык хәзерләнгән, колхозчылар орлык чистарту һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау эшләрен сайлау көненә—19 нчы январьга тәгәлләү өчен көрәшәләр. Колхозда кырга тирес чыгару, ашламалар хәзерләү һәм кар тоту эшләре яхшы оештырылган. Колхоз активистларыннан һәм стахановчылардан 70 кеше агроукуларга тартылган. Бу түгәрәкләрдә занятиеләр системалы рәвештә үткәрелә.

„Сталь" һәм Димитров исемендәге колхозларның җитәкчеләре исә пленум карарын үтәү өстендә тиешенчә эшләмәгәннәр. Бу колхозларда язгы чәчүгә хәзерлек эше гадәттән тыш начар тора. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт эшләре әле башланмаган да. Кышкы агрономия чаралары үткәрелми. Чәчүлек орлык җитәрлек күләмдә тупланмаган һәм орлыкларны чистарту эшенә дә керешмәгәннәр.

Райондагы башка күп кенә колхозларда да язгы чәчүгә хәзерлек эше начар тора. Райондагы колхозларда кар тоту планы 9 процентка, көл җыю 1 процентка гына үтәлгән. Кырга тирес чыгару һәм чәчүлек орлыкларны чистарту эшләре дә бик акрын бара.

Аннары сессиядә Сталин һәм Чапаев исемендәге колхозларда терлекләрне кышлатуга хәзерлекнең торышы турында докладлар тыңланды. Бу колхозларда терлекләрне кышлатуга начар хәзерләнгәннәр. Һәр ике колхозда терлекләрне үрчетү буенча дәүләт планы үтәлмәгән.

Сессия һәр ике мәсьәлә буенча конкрет карарлар кабул итте.

З. Салахеттинов.

СТАХАНОВЧЫЛАР СЛЕТЫ

ӘТНӘ, 28 декабрь. (Үз хәбәрчебездән телефон буенча). 27 нче декабрьдә Әтнә районында авыл хуҗалыгы стахановчыларының колхоз җитәкчеләре белән берлектә район слеты үткәрелде. Слетта 400 гә якын кеше катнашты. Авыл хуҗалыгы елының йомгаклары һәм 1941 нче елда район алдында торган бурычлар турында ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Ә. Галләмев доклад ясады.

Районның колхозлары югары уңыш өчен һәм терлекчелекне үстерү өчен көрәштә шактый уңышларга ирешкәннәр. Авыл хуҗалыгы эшләрен күпчелек колхозлар үткән елга караганда оешканрак төстә башкарганнар. 1939 нчы елда районда бөртекле культураларның уңышы гектарга уртача 7,30 центнер булса, быел гектардан уртача 10 центнер уңыш алынган. „Тарлау" колхозы, Ленин, Киров һәм „Ким" исемендәге колхозлар, „Ирек", „Чулпан" һәм Чапаев исемендәге колхозларда бөртекле культураларның уңышы һәр гектарга 15,70—12 центнер туры килә. Ленин исемендәге колхозның Минһаҗов иптәш бригадасы үзенә беркетелгән участкының һәр гектарыннан 16,50 центнер уңыш алган. Каганович исемендәге колхозның Фәридә иптәш Ханнанова звеносы 46 гектарлы участкының һәр гектарыннан 19,20 центнер уңыш алуга ирешкән.

Колхозлар ашлык тапшыру буенча дәүләт алдындагы йөкләмәләрне 100 процент үтәгәннәр. „Колхозларда җәмагать терлекчелеген үстерү чаралары турында" ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карарыннан соң колхозларда 74 яңа терлекчелек фермалары оештырылган.

Ләкин эштә җитешсезлекләр дә күп әле. Агротехника чараларын вактында үткәрмәү, хезмәтне дөрес оештырмау нәтиҗәсендә байтак колхозларда иген уңышы бик түбән. Мәсәлән, „Май", „Октябрьнең 13 еллыгы", „Кызыл Шахтер", „Яңа Кишет" һәм башка колхозларда уңыш гектарга 6—8 центнердан артмый. Вактында урып-җыймау нәтиҗәсе буларак, „Яңа Кишет" колхозында гына да 2 мең центнер чамасы ашлык югалтылган. Кайбер колхоз җитәкчеләрендә, бездә тары культурасы үсми, дигән ялгыш караш яшәп килә. Докладчы һәр гектардан 80—90 пот тары уңышы алган колхозлар мисалендә мондый карашларның һич нәрсәгә нигезләнмәгән булуын ачык күрсәтте.

Әтнә МТС ы (директоры иптәш Ишниязов) бик начар эшли. Тракторлар эше планын ул бары 64,9 процентка гына үтәгән. МТС җитәкчеләре тракторларны язгы чәчүгә хәзерләү буенча да ныклы чаралар күргәннәре юк. 20 нче декабрьгә бер генә трактор да ремонттан чыкмаган.

Слетта катнашучылар югары иген уңышы өчен, терлекләрне үстерү өчен көрәштә тупланган тәҗрибәләр белән уртаклаштылар. Конференцияне лаеклы каршылау өчен конкрет йөкләмәләр алып, слет Татарстанның барлык колхозчыларын, МТС эшчеләрен һәм җир органнары работникларын XVIII нче конференция исемендәге социалистик ярышка кушылырга чакырып мөрәҗәгать итте. Шушы ук слетта 1941 нче елның хуҗалык эшләрен үрнәк булырлык итеп башкару өчен Кызыл Юл районы белән ике арада төзелгән социалистик ярыш договорына кул куелды.

М. Хәмидуллин.

ТАТАРСТАН АССР КОЛХОЗЛАРЫНДА ҺӘМ СОВХОЗЛАРЫНДА 1941 НЧЕ ЕЛГЫ КЫШКЫ АГРОТЕХНИКА ЧАРАЛАРЫ ҺӘМ АШЛАМАЛАРДАН ФАЙДАЛАНУ ТУРЫНДА

Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советының һәм ВКП(б) Өлкә Комитетының 1940 нчы ел 27 нче декабрь карары

Колхоз һәм совхоз кырларының иген уңышын тагын да күтәрү, корылыкка каршы көрәшү һәм туфракның уңдырышын яхшырту эшендә кышкы агротехника чараларын тулысынча һәм вакытында үткәрүнең һәм тирестән, шулай ук башка төрле жирле ашламалардан файдалануның гадәттән тыш әһәмияте барлыгын исәпкә алып, Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы карар бирәләр:

1. Кышкы агротехника чараларын үткәрү һәм ашламалардан файдалану буенча Татарстан АССР Жир Эшләре Халык Комиссариаты тәкъдим иткән түбәндәге планны расларга һәм аны 1941 нче елга районнар буенча түбәндәгечә бүләргә:

а) колхозларда 1 миллион гектар мәйданда кар тоту;

б) 6 миллион тонна тирес чыгару;

в) 43.100 тонна көл җыю;

г) 20 мең тонна кош тизәге җыю;

д) көзге чәчүлекләр өчен 50.300 тонна компост-фекаль ашламалар хәзерләү һәм алар белән жир ашлау;

е) ашлама өчен колхозларда 18 мең тонна известь хәзерләү һәм 300 мең тонна торф чыгару;

ж) 6 мең гектар мәйданда көлсу ачы туфракларны известьлау;

з) колхозларда яшел ашламага 1941 нче елгы пар басуына 1 мең гектар жиргә чина һәм 100 гектар жиргә люпин чәчү һәм орлык өчен 200 гектар жиргә люпин чәчү (беренче номерлы кушымта буенча).

2. Тирес чыгару буенча еллык планның 70 проценты 1941 нче елгы язгы чәчүгә кадәр үтәлергә тиеш дип билгеләргә.

3. Совхозлар буенча 1941 нче елга кышкы агротехника чараларының һәм ашламалардан файдалануның Татарстан АССР Совхозтрестлары тәкъдим иткән планнарны расларга.

Совхозтрестларның директорларын,—Зыбин, Трофимов, Михайлов һәм Әхмәтҗанов иптәшләрне,—кышкы агротехника чаралары һәм ашламалардан файдалану планнарын 3 көн срок эчендә һәрбер совхозга җиткерергә мәҗбүр итәргә.

4. Район советлары башкарма комитетлары председательләрен, ВКП(б) райкомнары секретарьларын, район жир бүлекләре мөдирләрен һәм МТС директорларын, районнар буенча расланган планнарга туры китереп, түбәндәгеләргә мәҗбүр итәргә:

а) кышкы агротехника чаралары планын 1941 нче елның 5 нче январеннан соңга калмыйча колхозларга җиткереп, һәрбер колхозда кырчылык бригадалары һәм звенолар өчен унар көнлек заданиеләр билгеләргә;

б) 1941 нче елның 10 нчы январена кадәр барлык районнарда, кышкы агротехника чараларын оештыру һәм үткәрү техникасы мәсьәләләре буенча колхоз председательләренең, кырчылык бригадалары бригадирларының, звеноводларның һәм хата-лаборатория мөдирләренең куст киңәшмәләрен үткәрергә;

в) бик тизлек белән щитларны куплап хәзерләүне һәм аларны кырларга урнаштыруны оештырырга, шул ук вакытта уҗым чәчүлекләрендә, күп еллык үләннәр чәчүлекләрендә һәм кукса плантацияләрендә кар тотуны беренче чиратта үткәрүне тәэмин итәргә;

г) 1941 нче елга тиресне иң күп күләмдә җыю буенча колхозның һәм совхозның һәрбер терлекчелек бригадасына һәм һәрбер ат абзарына ныклы заданиеләр билгеләргә;

д) һәрбер колхозда һәм совхозда тиресне бары тик тирес саклау торган урында гына саклауны оештырырга, шуның өчен һәрбер колхозга һәм совхозга гади типтагы тирес саклау урыннары төзү буенча заданиеләр бирергә һәм конкрет шартлардан чыгып бу төзелешне тәмам итү срокларын билгеләргә һәм бу эшкә системалы рәвештә контроль ясап торуны тәэмин итәргә.

Колхозларга һәм совхозларга 100 баш эре терлектән ике ярым—өч ай эчендә җыела торган 300 тонна тиресне саклау исәбеннән чыгып тирес саклау урыннары тәзергә бирергә.

5. Татарстан АССР Жир Эшләре Халык Комиссариатына, 3 көн срок эчендә колхозларга тирес саклау урыннары төзү буенча гадиләштерелгән типовой проект һәм инструкция җибәрергә мәҗбүр итәргә.

Колхозларда тирес саклау урыннарын вакытында төзү өчен җаваплылыкны колхоз председательләренә, совхозларда—совхоз директорларына, ә гомумән район буенча район жир бүлеге мөдиренә йөкләргә.

6. Тирес хуҗалыгын дөрес оештыру өчен, шулай ук тирес һәм башка төрле жирле ашламаларны җыю һәм алардан файдалану планын үтәү өчен җаваплылык колхозларда колхоз председательләренә һәм совхоз директорларына, ә район буенча—район жир бүлекләренең баш агрономнарына йөкләнә дип билгеләргә.

Терлекчелек фермаларында һәм ат абзарларында тирес җыю һәм аны саклау өчен җаваплылыкны фермалар мөдирләренә һәм ат караучыларга, тиресне кырда дөрес саклау һәм аннан файдалану өчен җаваплылыкны кырчылык бригадалары бригадирларына йөкләргә. Моннан соң тиресне чокырларга ташлау һәм бөәләр ясау өчен тирестән файдалануда хуҗалыксызлык күрсәтүдә гаепле булган кешеләрне бик каты җавапка тартырга һәм бу хуҗалыксызлыкны җәмагать байлыгына саксыз караш дип һәм уңышны күтәрү чараларын өзү дип карарга.

7. Колхоз председательләрен,—колхозларның тиресне, көлне, кош тизәген якындагы район үзәкләреннән, шәһәрләрдән, тимер юл станцияләреннән, совет, сәүдә-кооператив һәм башка учреждениеләрдән, предприятиеләрдән һәм мәктәпләрдән колхоз кырларын ашлау өчен ташуларын тәэмин итәргә мәҗбүр итәргә.

Колхозларга тирес чыгышын арттыру, аның сыйфатын югарыртыру һәм тирес суының югалуын бетерү өчен, торф ятма урыннары булган районнарда барлык колхозларның терлекчелек фермаларында һәм ат абзарларында торф астына түшәү өчен файдалануны оештырырга, шулай ук, компостлар хәзерләү һәм тиресне ташландыклардан (ишек алдыннан, урамнардан) ташып алуны авыл советлары аркылы оештырырга.

Шул ук вакытта, авыл хуҗалыгы артеле уставының 6 нчы параграфы нигезендә, колхоз кырларын тиресләү өчен колхозчыларның шәхси хуҗалыкларындагы тиресне алу һәм тиресне ашлау өчен файдаланырга итәргә.

8. Татарстан АССР Жирле Промышленность Халык Комиссариатын һәм Госпланны,—1941 нче елның 1 нче февраленнән соңга калмыйча, 1941-1942 нче елларда Түбән Кама фосфоритлары чыгару планын Татарстан АССР Совнаркомы карамагына кертергә һәм Татарстан АССР ның башка районнарында фосфоритлар чыгару буенча кузату-геология эшләре оештырырга мәҗбүр итәргә.

9. Татарстан АССР Жир Эшләре Халык Комиссары иптәш Мәрданов һәм Госплан председателе иптәш Цибинга,—бер ай срок эчендә, 1941 нче елны известь хәзерләү планын, шулай ук Татарстанның тоньяк-көнбатыш районнарындагы колхозларда куллану өчен, известь чыгару урыннары турындагы мәгълүматларны кубесендә, известь чыгару планын тәкъдим итәргә.

10. Сельхозснабның мәдире иптәш Кабировка ашламаларны тапшыруны тәэмин итәргә:

а) 1941 нче елны минерал ашламалар өчен булган складларга ремонт ясарга;

б) складларда ашламаларны дөрес саклауны тәэмин итәргә һәм тимер юл станцияләренә килгән минераль ашламаларны склад бинаменн тапшыруны тәэмин итәргә;

в) ашламаларны, складлардан тыш, бары тик шуның өчен ясалган, түбәле площадкаларга гына бушатырга;

г) ашламаларны Сельхозхимснаб складларыннан улчамичә һәм лаборатория анализы ясамыйча колхозларга һәм совхозларга җибәрүне тыярга.

11. Совхоз председательләрен һәм совхоз директорларын түбәндәгеләргә мәҗбүр итәргә:

а) 1941 нче елның 1 нче февраленә кадәр Сельхозхимснаб складларыннан минерал ашламаларны тулысынча алып бетерүне тәэмин итәргә;

б) ашламаларның керүенә һәм аларны ашлана торган участкыларга тарату өчен җибәрүгә үлчәү ягыннан нык исәп алып барырга;

в) минерал ашламаларны ачык һавада, яки яңгыр үтә торган яраксыз биналарда саклауны тыярга.

12. Татгосиздатка һәм Татарстан АССР Жир Эшләре Халык Комиссариатына, жирле һәм минерал ашламаларны саклау һәм алардан файдалану буенча 1941 нче елның 1 нче февраленнән соңга калмыйча популяр плакатлар һәм инструкция чыгарырга тәкъдим итәргә.

13. ВЛКСМ Өлкә Комитетын,—Татарстан АССР колхозларында һәм совхозларында кышкы агротехника чаралары һәм ашламалардан файдалану планын үтәү эшендә комсомол оешмаларының катнашуы буенча конкрет чаралар билгеләргә мәҗбүр итәргә.

14. Өлкә һәм район газеталары редакторларын һәм Татрадиокомитетны,—кышкы агротехника чараларын үтәү (кар тоту, тирес җыю һәм аны саклау һ. б.) һәм ашламалардан файдалану буенча алдынгы колхозлар һәм совхозлар тәҗрибәсен популярләштерүне һәм пропагандалауны киң күләмдә оештырырга мәҗбүр итәргә.

15. Ашламалар куллану мәсьәләләрен агрозоотехника түгәрәкләрендә һәм стахановчылык мәктәпләрендә өйрәнүгә ВКП(б) райкомнарының, район жир бүлекләренең һәм колхоз правлениеләренең игътибарын аеруча юнәлдерергә һәм аларга колхозчылар һәм райондагы партия, совет активы өчен, авыл хуҗалыгы белгечләре көче белән, бу темаларга популяр лекцияләр үткәрүне кинрәк кулланырга тәкъдим итәргә.

16. Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы, район Советларының башкарма комитетларыннан, ВКП(б) райкомнарыннан, жир органнарыннан, колхоз правлениеләреннән, МТС һәм совхоз директорларыннан, кышкы агротехника чараларын үткәрүгә һәм ашламалардан файдалануга игътибарсыз карашны бетерүне һәм, массовый-политик эшне җәелдерү нигезендә, барлык культураларның уңышын күтәрү өчен көрәштә кышкы агротехника чаралары һәм ашламалардан файдалану планын үтәү һәм арттырып үтәү буенча социалистик ярышны һәм стахановчылык хәрәкәтен кинрәк оештыруны таләп итәләр.

Татарстан АССР Совнаркомы Председателе
С. ГАФИЯТУЛЛИН.

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты Секретаре
МАТВЕЕВ.

Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советының һәм ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросының 1940 нчы ел 27 нче декабрь карарына кушымта № 1

ТАТАРСТАН АССР КОЛХОЗЛАРЫНДА 1941 НЧЕ ЕЛГЫ КЫШКЫ АГРОТЕХНИКА ЧАРАЛАРЫ ҺӘМ АШЛАМАЛАРДАН ФАЙДАЛАНУ ПЛАНЫ

РАЙОН ИСЕМНӘРЕ	Кар тоту (мең га белән)	Тирес чыгару (мең тонналар белән)	Көл җыю (тонналар белән)	Кош тизәге җыю (тонналар белән)	Компостфикаль ашламалар җыю һәм кырга чыгару (тонналар белән)	Торф хәзерләү (мең тонналар белән)	Известьләү (га белән)	Яшел ашлама өчен чина утырту (га белән)	Люпин чәчү: Яшел ашлама өчен (га белән)	Люпин чәчү: Орлык өчен (га белән)
Әгерже	9	87	570	275	500	12,0	—	—	—	—
Азнакай	15	100	400	190	1000	—	—	—	—	—
Аксубай	11	77	700	300	600	6,0	—	—	—	—
Актаныш	15	131	940	480	800	10,0	—	—	—	—
Акташ	27	98	600	200	1300	3,0	—	—	—	—
Алексеевский	14	70	400	200	400	7,0	—	—	—	—
Әлки	22	65	400	200	5 0	9,0	—	—	—	—
Әлмәт	17	110	6 0	250	1200	3,0	—	—	—	—
Апас	20	90	950	40	8 0	3,0	—	—	—	—
Арча	24	140	1100	610	1000	6,0	600	—	—	—
Әтнә	16	120	890	435	400	12,0	540	—	—	—
Баулы	11	82	600	200	1000	—	—	—	—	—
Балтач	12	67	540	265	500	1,0	300	—	—	—
Биләр	19	69	400	200	500	4,0	—	—	—	—
Бондюг	15	86	560	265	1000	1,0	500	—	—	—
З. Тархан	10	53	700	300	550	—	—	—	—	—
Бөгелмә	13	88	420	210	2000	—	—	—	—	—
Буденный	16	63	850	350	700	—	—	—	—	—
Буа	18	90	940	400	850	1,0	—	—	—	—
Ю. Ослан	11	56	500	200	400	1,0	—	—	—	—
Ворошилов	20	122	620	290	500	5,0	—	—	—	—
Биектау	12	53	500	200	400	1,0	400	100	10	20
Чүпрәле	17	75	1200	500	1000	9,0	—	—	—	—
Дәбъяз	16	72	900	350	750	4,0	350	100	10	20
Алабуга	20	130	880	435	800	8,0	500	50	—	—
Заинский	22	97	620	250	2000	7,0	—	—	—	—
Калинин	17	185	890	485	800	—	—	—	—	—
Кайбыч	21	130	1200	500	1000	12,0	—	—	—	—
Кама Тамагы	10	44	500	200	400	—	—	—	—	—
Кызыл Армия	13	45	300	180	400	—	—	—	—	—
Кызыл Йолдыз	15	130	1000	470	900	1,0	—	150	20	40
Кызыл Юл	15	92	740	375	700	3,0	450	—	—	—
Красный Бор	15	118	760	355	700	7,0	—	200	30	60
Куйбышев	17	94	450	200	500	7,0	—	—	—	—
Кузнечиха	17	60	400	200	500	10,0	—	—	—	—
Кукмара	20	110	980	480	900	0,5	250	—	—	—
Лаеш	15	82	850	350	700	10,0	—	50	—	—
Мамадыш	16	117	810	390	700	—	—	50	—	—
Минзәлә	21	190	1100	600	1000	7,0	—	—	—	—
Мөслим	16	162	820	415	700	—	—	—	—	—
Яңа Чишмә	19	100	500	320	700	3,0	—	—	—	—
Яңа Писмән	10	67	400	150	1000	1,0	—	—	—	—
Норлат	14	85	850	350	700	12,0	—	—	—	—
Октябрь	14	95	400	300	700	—	—	—	—	—
Беренче Май	21	120	500	300	2000	8,0	—	—	—	—
Питрәч	19	77	700	300	550	14,0	400	100	10	20
Балык Бистәсе	18	122	790	385	700	6,0	—	—	—	—
Саба	20	142	1000	500	9 0	8,0	330	—	—	—
Сарман	18	108	500	270	1000	10,0	—	—	—	—
Столбище	14	59	600	250	500	4,0	300	100	10	20
Тәкәнеш	17	146	1100	525	900	—	300	—	—	—
Тельман	8	62	450	200	400	8,0	—	—	—	—
Тәмте	12	52	450	200	400	—	—	—	—	—
Тәтеш	15	65	700	300	550	1,0	—	—	—	—
Тымытык	11	76	400	150	1000	—	—	—	—	—
Теләче	15	115	770	370	700	10,0	500	—	—	—
Ч пья	11	70	530	255	500	10,0	2 0	—	—	—
Чаллы	18	145	880	460	800	8,0	—	—	—	—
Чистай	18	80	550	300	600	2,0	—	—	—	—
Ширәмәт	16	105	700	300	700	6,0	—	—	—	—
Шөгер	21	103	600	200	1200	8,5	—	—	—	—
Юдино	8	50	550	210	450	7,0	—	100	10	20
Ютазы	13	106	600	250	2000	3,0	—	—	—	—
ТАССР буенча барлыгы:	1000	6000	43100	20000	50300	300,0	6000	1000	100	200

Язгы чәчүгә хәзерлек начар

Балтач районы, „Кызыл Октябрь" колхозында язгы чәчүгә хәзерлек эше бик начар бара. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау эше 35 процентка гына үтәлгән. Колхозда 1.250 центнер чәчүлек орлыгы чистартылырга тиеш булса да, бары 80 центнер гына чистартылган. Кар тоту, басуга тирес чыгару һәм башка төрле агрономия чаралары куллану эшенә бөтенләй керешелмәгән. Агрономия түгәрәкләре эшләми.

Бригадирлардан Зарипов, Мәрданев, Галиуллин һәм Мәхәмәдиевләр кар тоту, басуга тирес чыгару һәм көл җыйнау буенча колхоз идарәсе тарафыннан бирелгән нарядларны үтәмиләр.

А. Шәфигуллин.

Юридик институтның ВКП(б) тарихын отличного өйрәнүче студентларыннан бер төркем. Сулдан уңга: Г. Абраров, В. Белов, Е. Добрянский һәм В. Лисиченко иптәшләр институтның китапханәсендә. И. Галиев фотосы.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

Цех партоешмаларына ярдәм кирәк

Партия хуҗалыгының яхшы саклануына, партия документларының дөрес һәм яхшы оформить ителүенә, барыннан да элек, партоешма секретаре җаваплы. Ләкин Вахитов исемендәге жиркомбинат заводларындагы кайбер башлангыч партоешма секретарьлары бу җаваплылыкны сизеп җиткермиләр әле.

Шәм заводы янындагы партоешма (секретаре иптәш Савельева) комбинат күләмендә зур оешмаларның берсе. Ләкин бу оешманың эшендә җидди кимчелекләр бар. Мәсәлән, январь, май, июль, август һәм ноябрь айларында партия җыелышлары бөтенләй үткәрелмәгән. Үткәрелгән җыелышларның да протоколлары тиешенчә оформить ителмиләр. Кайбер протоколларда җыелыш председателенең һәм секретареның имзалары юк. 25 нче февральдә үткәрелгән отчет-сайлау җыелышы протоколы дөрес оформить ителмәгән. Мәсәлән, отчет докладлы буенча чыгарылган карарның кереш өлешенең ике пункты язылганнан соң тавыш санау комиссиясе протоколы язылган һәм аннан соң карарның калган өлеше язылган. Моннан, отчет докладлы буенча карар кабул иткәнче сайлау үткәрелгәнме әллә дигән шик туа. Протоколда җыелыш председателенең һәм секретареның имзалары юк. Өч кешедән торган санау комиссиясе протоколында да секретарьның гына имзасы бар.

26 нчы сентябрь һәм 23 нче октябрьдә булган җыелышларда көн тәртибенә кертелгән 2 нче мәсьәләләрнең каралу-каралмавы турында протоколга язылмаган. „Без ул мәсьәләләрне карадык-каравын" ди секретарь иптәш Савельева. Ләкин протоколга ни өчен язылмый калганын белми.

Отчет докладлы буенча кабул ителгән карардан (бу карар 6 пункттан тора) башка карарлар һәр кайсы берәр пункттан гына һәм гомуми сүзләрдән генә торалар. Алар арасында дөрес булмаган карарлар да бар. Ләкин, ул ялгышларны партоешма секретаре иптәш Савельева да, партбюро секретаре иптәш Макутин да күрмәгәннәр.

Менә стеарин заводы янындагы партоешма. Бу оешмада коммунистларның җыелышларга йөрүләрен учетка алу дәфтәре бар. Анда һәр айның 1,10 һәм 20 нче көннәрендә коммунистларның җыелышка килү һәм килмәүләре турында билге ясалган. Димәк, бу исемлек буенча 10 ай эчендә 30 җыелыш үткән булып күренә. Ә фактта исә 1940 нчы елда ни бары 4 җыелыш үткәрелгән: Март, апрель, май, июль, август, сентябрь һәм ноябрь айларында җыелышлар булмаган. Партбюрога бары бер җыелыш протоколы тапшырылган. Хәтта 25 нче февральдә үткәрелгән отчет-сайлау җыелышы протоколы да партбюрога тапшырылмаган. Быел үткәрелгән 4 җыелышның икесендә өч мәсьәлә карала, ләкин бер төрле дә карар кабул ителми.

Механика цехында да (секретаре иптәш Рябинин) ел буена бары 4 тапкыр җыелыш үткәрелгән. Җыелыш протоколлары вак-вак кәгазьләргә генә язылган. Алар делога тегелмәгәннәр, башка кәгазьләр белән буталып яталар.

Бу оешмаларның өчесендә дә коммунистларның дөрес учетлары юк. Исемлеккә коммунистларның кайберләренең билет номерлары язылмаган. Шәм заводы янындагы партоешмада ВКП(б) членлыгына кандидатлар исемлегендә кандидатлык карточкасы номеры дигән графага да, туган елы графасына да „1939" яки „1932" дип язылган. Бу цифрларның нәрсә аңлатулары билгеле түгел.

Бу кимчелекләрнең сәбәбе нәрсәдә соң? Аның сәбәбе плансыз эшләүдә һәм игътибарсызлыкта. Бу оешмаларның берсендә дә еллар буена план төзелмәгән. „Безнең план төзегәнебез юк. Партбюро секретаре безгә, фәлән мәсьәлә белән партия җыелышы үткәрегез, дип кушкач кына без җыелыш үткәрәбез. Күп вакытларда без протокол язмыйбыз", ди механика цехы янындагы партоешма секретаре иптәш Рябинин.

Партбюро, аның секретаре иптәш Макутин заводлардагы партоешма секретарьлары белән планлы эш алып бармый. Партоешма секретарьларын эшкә өйрәтү йөзеннән чыгып бары бер киңәшмә үткәрелгән. Алардан килгән протоколларны укымый, хәтта протоколларның партбюрога килүен дә тикшерми.

ВКП(б) ның Сталин райкомы инструкторы иптәш Гафиятуллин бу партоешмаларда шактый еш була һәм андагы хәлләрне күрә. Ләкин партия хуҗалыгын тәртипкә салу буенча конкрет булышлык оештырмый.

Партия документларын оформить итүгә мондый карашны бетерергә, цехлардагы партоешмаларның планлы эшләрен булдырырга кирәк.

Г. Галиуллин.

Үтәлешне тикшермәүнең күңелсез нәтиҗәләре

„Красный Путь" заводы янындагы партоешмада отчет-сайлау җыелышы 1940 нчы елның 16 нчы февралендә булган. Җыелыш яна сайланган бюро алдына коммунистларның идея-политик дәрәҗәләрен күтәрү, производство планын сан һәм сыйфат ягыннан үтәүне тәэмин итү, комсомол һәм профсоюз оешмаларына җитәкчелекне көчәйтү бурычын куйган. Отчет-сайлау җыелышыннан соң партоешманың 22 тапкыр гомуми җыелышы булып, аларда 41 мәсьәлә каралган һәм 41 карар кабул ителгән. 22 тапкыр бюро утырышы булган һәм анда 30 мәсьәлә каралып, 30 га якын карар кабул ителгән.

Үткәрелгән җыелышларның санына, анда тикшерелгән мәсьәләләрнең күләменә караганда, бу оешмада эш начар түгел шикелле күренә. Ләкин, фактта исә отчет-сайлау җыелышы тарафыннан куелган иң әһәмиятле мәсьәләләр үтәлмичә киләләр. Завод начар эшләвендә дәвам итә. 20 нче июльдән 20 нче октябрьгә кадәр 3 ай вакыт эчендә генә дә 775 деталь брак итеп эшләнгән. Үткән елны 1 нче январьда заводта 105 стахановчы саналган булса, октябрь аенда аларның саны 73 кә генә калган.

Менә бу фактлардан соң үзеннән үзе бер сорау туа: план төзелгән, җыелышлар үткәрелгән, карарлар кабул ителгән, ә эштә борылыш ясалмаган, сәбәп нәрсәдә соң?

Моңа җавап бер генә: партия оешмасы җитәкчеләре үтәлешне тикшерүнең хәл иткеч әһәмиятен аңламаганнар. Моны раслау өчен бер генә факт китерик. Җыелышларда каралган 41 мәсьәләнең бары тик бер генә үтәлешне тикшерүгә карата булган. Ул да җыелышка хәзерлексез кертелгәнлектән, тиешле нәтиҗә бирмәгән. Җыелыш, икенче кат тикшерергә, дип карар чыгарган. Ләкин бу карар партбюро секретаре иптәш Кирюхинга йогынты ясамаган. 30 нчы октябрьдә булган җыелышның: „Үткәндә кабул ителгән карарларның үтәлешен тикшереп, алдагы җыелышка куярга" дигән карарыннан соң да бу өлкәдә борылыш ясалмаган. Шушы рәвешле үтәлүне тикшерү эшенә җавапсыз карау нәтиҗәсендә, партоешманың бик күп карарлары үтәлмичә калганнар. Сыйфат өчен көрәшнең тиешле дәрәҗәгә куелмавы, стахановчылык хәрәкәтенең киң җәелмәве нак менә шуның—үтәлешне тикшермәүнең күңелсез нәтиҗәсе булып тора да.

Ә. Ибраһимов.

ВЛКСМ ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ИКЕНЧЕ ПЛЕНУМЫ

25—27 нче декабрьдә ВЛКСМ ның Татарстан Өлкә Комитетының икенче пленумы булып узды. Пленум Ютазы һәм Тәтеш район комсомол оешмаларының 1941 нче елгы язгы чәчүгә хәзерлектә катнашулары турындагы, Татарстан АССР дагы пионер оешмаларының эше турындагы һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының „Комсомол активын физик хәзерләү турында“гы карарының үтәлеше турындагы мәсьәләләрне тикшерде.

Беренче мәсьәлә буенча ВЛКСМ ның Ютазы райкомы секретаре Абдуллина һәм ВЛКСМ ның Тәтеш райкомы секретаре Шәрәпов иптәшләр доклад ясадылар. Иптәш Абдуллина язгы чәчүгә хәзерлектә күп кенә комсомолецларның актив катнашуларын әйтеп үтте. ВКП(б) Өлкә Комитетының III нче пленумы карарлары актив җыелышында һәм башлангыч оешмалар җыелышларында тикшерелгән. „8 нче март“ колхозы янындагы комсомол оешмасы (секретаре иптәш Газизуллин) язгы чәчүгә хәзерлектә аеруча актив катнаша. Биредә 9 комсомолецның алтысы турыдантуры производствода эшли. Колхоз үзенә җитәрлек күләмдә чәчүлек орлыклар хәзерләп куйды. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау тәмамланды. Агрозоотехника укулары яхшы оештырылды. Колхозчылар арасында социалистик ярыш җәелдерелде.

Тәтеш районының „Подъем“ колхозындагы комсомол оешмасы авыл хуҗалыгы инвентарьларына ремонт ясауның барышын, чәчүлек орлыкларның сакланышын, атларны тәрбияләүнең торышын тикшерде. ВКП(б) Өлкә Комитетының III нче пленумы карарларын тикшереп, комсомолецлар язгы чәчүгә хәзерлек буенча конкрет чаралар билгеләделәр.

Шулар белән бер рәттән, язгы чәчүгә хәзерлек буенча Ютазы һәм Тәтеш районнарындагы комсомол оешмаларының эшендә зур гына кимчелекләр дә бар. ВЛКСМ ның Ютазы райкомы үз районының экономикасын начар белә, җир органнары белән элемтәсе җитәрлек түгел. Колхозлар белән дә бик начар элемтә тота. Тәтеш районындагы комсомол оешмаларының кайбер секретарьлары: Хөснеттинова („Красный путиловец“ колхозы), Сугуцкий („Самолет“ колхозы), Иванова („Завет Ильича“ колхозы) иптәшләр агротехниканы белмиләр. ВЛКСМ райкомы 40 тракторчы хәзерләү турында йөкләмә алган иде, ләкин 16 гына тракторчы хәзерләде.

Беренче мәсьәлә буенча фикер алышуларда ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Матвеев зур речь белән чыгыш ясады. Ул язгы чәчүгә хәзерлек уңае белән комсомол оешмалары алдында торган бурычларга киң күләмдә тукталды. Беренче мәсьәлә буенча фикер алышуларда 15 кеше катнашты.

Икенче мәсьәлә буенча пленум ВЛКСМ Өлкә Комитеты секретаре иптәш Сабитованың докладын тыңлады. Аннары ВЛКСМ Өлкә Комитеты секретаре иптәш Доронин „Комсомол активын физик хәзерләү турында“ ВЛКСМ Үзәк Комитеты карарының үтәлеше турындагы мәсьәлә буенча доклад ясады. Докладчы да, шулай ук фикер алышуларда чыгыш ясаучы иптәшләр дә, бу өлкәдәге беренче уңышларны күрсәтеп үттеләр һәм физик культураның кирәклеге турында күп сөйләнеп тә, практик яктан бер нәрсә дә эшләмәүче активистларны кискен рәвештә тәнкыйть иттеләр.

Пленум, тикшерелгән барлык мәсьәләләр буенча да карарлар кабул итте. (ТатТАСС).

Югалтуларсыз эшләргә

Чималны һәм фурнитураларны экономлы рәвештә тоту, югалтуларсыз эшләү һәрбер предприятие алдында сугышчан бурыч булып тора һәм бу бурычны үтәү продукциянең үзенә төшү бәясен киметүгә бәйләнгән.

„Спартак“ комбинатында бу таләпне намус белән үтәүче, социалистик милекне сизгер саклаучы стахановчылар аз түгел. Мәсәлән, тегү цехында итекләргә табан салу процессында эшләүче Андреева, Тарасенкова, Назарова һәм башка иптәшләр һәр ай саен 22—18 килограмм тимер кадакка экономия ясыйлар. Штамп цехында эшләүчеләрдән иптәш Карпов быелның 9 аенда 725 килограмм, иптәш Меркулов 936 килограмм күн табанлык материалларына, кисү цехында итек заготовкаларын кисү эшен башкаручы иптәш Зарипов 11 ай эчендә 308 метр, иптәш Хәбибуллина 174 метр кыйммәтле күн товарларга экономия ясауга ирешкәннәр.

Ләкин бу иптәшләрнең үрнәкле эш тәҗрибәләре башкаларга күчерелми. Нәтиҗәдә исә гомумән комбинат күләмендә югалтулар зур күләм алган. Мәсәлән, тегү цехы буенча октябрь аенда гына да 314 килограмм кадак, штамп цехында 104 килограмм резина клее һәм башкалар нормадан артык тотылган. Шуның аркасында бу цехлар октябрь аенда 4.100 сумлык зарар күрделәр.

Полувал һәм хром заводларында да югалтулар зур. Полувал заводы буенча, мәсәлән, октябрь аенда 4.910 килограмм чимал артык тотылган. Ә хром заводы буенча начар сыйфатлы продукция исәбенә 100 мең сумлык зарар күрелгән.

Комбинат җитәкчеләре бу фактлардан тиешле нәтиҗә ясап, югалтуларга каршы көрәшне көчәйтергә тиешләр. *Җ. Сәфәргалиева.*

Чит илләрдә

АНГЛИЯ - ГЕРМАНИЯ СУГЫШЫ

ГЕРМАНИЯ ХӘБӘРЛӘРЕ

БЕРЛИН, 27 декабрь. (ТАСС). Германия информация бюросы Германия армиясе верховный командованиесенең түбәндәге сводкасын тапшыра: „Германия авиациясе рождество бәйрәменең икенче көнне—26 нчы декабрьдә дә Англиягә бернинди һөҗүмнәр ясамады. Англия самолетлары исә үз көнне һәм 27 нче декабрьгә каршы төндә, без оккупацияләгән Франциядәге аэродромнарга, порт корылмаларына һәм шәһәрләргә бомбалар ташладылар. Үлүчеләр һәм яраланучылар бар. Хәрби объектлар зарарланмады. Англиянең бер самолеты бәреп төшерелде. Еракка ата торган артиллерия 27 нче декабрьдә иртә белән дошманның Ла-Маншта гы карабларына атты“.

Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, бүген иртә белән Германиянең еракка ата торган артиллериясе дошманның Ла-Маншта гы карабларын һәм Дувр портын уңышлы рәвештә тупка тоткан.

БЕРЛИН, 27 декабрь. (ТАСС). Германия информация бюросы хәбәр итә:—Өстәмә хәбәрләргә караганда, 26 нчы декабрьдә кич Англия самолетлары Бордога гына түгел, бәлки Сен Малога, Динарга һәм Лессейгә дә һөҗүм иткәннәр. Ләкин бу һөҗүмнәр уңышсыз чыккан. Хәрби объектлар зарарланмаган.

АНГЛИЯ ХӘБӘРЛӘРЕ

ЛОНДОН, 27 декабрь. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 27 нче декабрьгә каршы төндә Англия өстендә Германия самолетлары күренмәгән. 24—26 нчы декабрьдә көндезге операцияләр бик кечкенә күләмдә генә булган. Соңгы өч тәүлек эчендә Англия—Германия һава фронтында башланган тынлык—Германия авиациясенең Англиягә массовый һөҗүмнәр башлау вактыннан бирле иң озакка сузылган тынлык булды.

25 нче декабрьдә Па-де-Кале бугазында Германиянең Англиягә басып керүе өчен иң уңайлы һава булган. Тыныч диңгез өстенә томан төшкән. Немецләрнең нинди генә минутта булса да басып керергә тырышулары ихтималы булганлыктан, сакчы отрядлар икеләтә көчәйтелгәннәр, еракка ата торган орудиеләр батареяләренең командирлары һәр вакыт хәзер торганнар, диңгез сакчылыгы караблары көндез һәм төнлә күзәтү эше алып барганнар.

Бүген иртә белән, соңгы көннәрдә беренче тапкыр буларак, Германиянең Франция ярына куелган еракка ата торган орудиеләре Дувр районына яңадан бик озак атып торганнар. Корбаннар юк һәм материаль зиан килмәгән.



Италия - Греция сугышы. Рәсемдә: Италиянең кыр орудиесе фронтта.
ТАСС фотосы.

ИТАЛИЯ - ГРЕЦИЯ СУГЫШЫ

АФИНА, 27 декабрь. Рәсми рәвештә хәбәр ителүенчә, уңышлы барган җирле операцияләр кичә грек гаскәрләренең тагын да алга баруларына һәм яңа позицияләр алуларына ярдәм иткән. Күп кенә итальяннар плен алынганнар һәм шактый күп сугыш материаллары кулга төшерелгән.

Грециянең эчке районнарында кичәге көн тыныч үткән.

НЬЮ-ЙОРК, 27 декабрь. Ассошиэйтед Пресс агентлыгының хәбәритүенә караганда, Греция гаскәрләре Поградецтан 15 миль төньяктарак Лин шәһәрен алганнар.

БЕЛГРАД, 27 декабрь. „Политика“ газетасының язуына караганда, рождество бәйрәмнәре вактында фронтта сугыш хәрәкәтләре туктатылмаган.

Фронтның көньяк өлешендә, Химарадан төньяктарак, грек гаскәрләре бик каты сугышлардан соң итальяннар ташлап киткән позицияләргә таба баруларында дәвам итәләр.

Грециянең һава көчләре, коры җир гаскәрләре белән актив рәвештә бергәләшеп хәрәкәт итеп, дошманның батареяләрен һәм пулемет ояларын бомбага тотканнар. Англия авиациясе Италия гаскәрләренең тылына берничә тапкыр һөҗүм ясаган һәм фронтка таба килүче итальяннар колонналарын һәм аларның юлларын бомбага тоткан.

Грек гаскәрләре Аргирокастроннан Тепеленегә таба, Химарадан Валонага һәм Бератка таба һөҗүм итәләр.

Италия частьләре Бират һәм Валона тирәсендәге әһәмиятле стратегик биеклекләргә урнашканнар. Алынган хәбәрләргә караганда, монда итальяннарга өстәмә көчләр килергә тиеш.

„Време“ газетасы, 25 һәм 26 нчы декабрьдә Тепелене һәм Клисура секторында бик каты сугыш булганлыкны хәбәр итә. Грек гаскәрләре еш кына һөҗүмгә күчәләр. (ТАСС).

Африкада сугыш хәрәкәтләренең барышы

ЛОНДОН, 27 декабрь. Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, кичә Англиянең Якын Көнчыгыштагы һава көчләре командованиесе бернинди дә белдерү игълан итмәгән. Әйтүләренә караганда, командование 25 нче декабрьдә дошман территориясен бомбага тотудан тыелып торырга карар биргән. Ул көнне авиациянең хәрәкәтләре разведка очышлары белән генә чикләнгән.

Судан фронтында Англия частьләре Кассалы секторында торган саен активлаша баралар. Алар дошманны бөтен чик буе линиясе буйлап кысрыклыйлар, дошманга каршы тозаклар коралар. Кассалыны һәм Төньяк Абиссинияне саклап калу өчен Асмарада һәм Агордатта (Эритрея) Италиянең зур армиясе тупланган. Шулай ук Италия гаскәрләре Гондара, Тан күле тирәләрендә һәм Аддис-Абеба районында да тупланганнар.

РИМ, 27 декабрь. Стефани агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Италия авиациясенең төп бурычы Англиянең Урта диңгездәге, Якын Көнчыгыштагы, Кызыл диңгездәге һәм шулар белән күрше зоналардагы терәк пунктларын юк итүдән гыйбарәт. Италия авиациясе хәрәкәтләре районы бер-береннән гаять зур ара белән аерылган 8 секторга бүленгән. Тәэмин итү башлыча диңгез юлы белән алып барыла.

НЬЮ-ЙОРК, 27 декабрь. Юнайтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, англичаннар, өзлексез рәвештә бомбага тоту юлы белән, итальяннарны Бардия тирәсендәге ныгытмалар линиясеннән акрынлап шәһәрнең үзенә чигенергә мәҗбүр итәләр. Англичаннар, Бардияга килә торган урында 8 миль зурлыктагы калган зонаны чолгап алып, хәл иткеч һөҗүмгә хәзерләнәләр. (ТАСС).

ИТАЛИЯ СВОДКАСЫ

РИМ, 27 декабрь. (ТАСС). Стефани агентлыгы Италия командованиесенең түбәндәге сводкасын тапшыра: „Киренаиканың чик буе зонасында һәр ике яктан артиллерия һәм патрульләр хәрәкәте дәвам итә. Италия истребительләре дошманның бик күп самолетлардан торган берләшмәсенә һөҗүм итеп, 3 самолетны бәреп төшерделәр. Безнең бер самолетыбыз үз базасына кайтмады.

Греция фронтында артиллериядән атышу һәм җирле характердагы операцияләр булды. Безнең самолетлар порт корылмаларын, пароходларны һәм коры җир операцияләренә турыдантуры кагылышы булган объектларны бомбага тоттылар.

Көнчыгыш Африкада әйтерлек үзгәрешләр юк“.

Финляндия президенты яңа хөкүмәт төзүне Пехконенга тапшырды

ХЕЛЬСИНКИ, 27 декабрь. (ТАСС). Финляндия президенты яңа хөкүмәт төзүне Улеаборг губернасы губернаторы, аграр партия члены Пехконенга тапшырды. Пехконен ризалык бирде һәм Улеаборгдан Хельсинкига килергә чыкты.

Пехконен 1882 нче елны туган. 1914 нче елны сейм депутаты булган. 1920 нче елдан 1921 нче елга кадәр—җир эшләре министре. 1925 нче елдан—Улеаборг губернасының губернаторы.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

Үзәк Кытайда. Хубэй провинциясенең көньяк-көнчыгышында кытай гаскәрләре японнарны Янсинь шәһәре районындагы позицияләрдән бәреп чыгарганнар. Шулай ук кытайлар японнарның Янсинь белән Цзюцзян арасындагы (Цзянси провинциясе) юлларын кискәннәр.

Төньяк Кытайда. Шаньси провинциясенең көньяк-көнчыгыш өлешендә японнар Чжанцзы—Хугуань районында һөҗүм ясаганнар, ләкин чигенергә мәҗбүр булганнар.

Хэнань провинциясенең төньягында кытай партизаннары Кайфын районында тимер юл күперен шартлатканнар.

Көньяк Кытайда. Хайнань атавында кытай партизаннарының актив хәрәкәтләре дәвам итә. Кытайлар атауның көньяк-көнбатыш өлешендә япон гаскәрләренең терәк пунктларына һөҗүм итәләр.

Кантон районына японнарның 20.000 нән артык солдатлары тупланган. Бу районның аэродромнарында 100 бомбардировщик һәм кимендә 120 истребитель бар.

* * *

22 һәм 23 нче декабрьдә японнар Гуандун провинциясендәге берничә шәһәрне бомбага тотканнар. Мисы бухтасы ярындагы Гуйчжун шәһәрен бомбага тоткан вакытта японнар Швейцария миссиясе бинасына да бомбалар ташлаганнар. Юнайтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, бомба шартлаудан бу миссиянең башлыгы Мейерхольт үлгән.

27 декабрь. (ТАСС).

Таи һәм Франция Һинд-Кытае гаскәрләре арасында бәрелешләр

НЬЮ-ЙОРК, 27 декабрь. (ТАСС). Ассошиэйтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Франция даирәләре, 25 нче декабрьдә Франция Һинд-Кытае белән Таи арасындагы чиктә булган сугышның соңгы ике атнада иң җидди сугыш булганлыгын әйтәләр. Такек якынында артиллериядән атышу булган. Таи жандармериясе Меконг елгасындагы кайбер атауларга һөҗүм ясаган. Франция Һинд-Кытае артиллериясе дә үз чиратында Таи жандармериясе биналарына аткан. Шулай ук чикнең көньяк участкысы буенда да бәрелешләр бара.

Шул ук агентлыкның Бангкоктагы хәбәрчесе Таиның белдерүен тапшыра. Бу белдерүдә Таи артиллериясенең 25 нче декабрьдә Франция Һинд-Кытаеның гаскәрләрен төяп Меконг елгасыннан үтеп бара торган ике транспортын батырганлыгы әйтелә.

ЮГАЛГАН ДАН

Арбалар һәм чаналарның җитәрлек булмавы 1940 нчы елда Алабуга районы колхозларының эшендә зур тоткарлык ясады. Арбалар җитешмәгәнлектән урып-җыелган ашлык вактында скертләнмәде, шуның аркасында колхозлар зур югалтуларга дучар булдылар. Дәүләткә ашлык, бәрәңге һәм яшелчә тапшыру эшенең озакка сузылуы да арбалар җитешмәүгә нык бәйләнгән иде. Район оешмалары ашлык ташу графигын биргәндә колхоздагы атларны гына искә алып эшләделәр. Һәр көнне 1.200 баш ат ашлык ташырга тиеш иде. Ә фактта исә ашлык ташуга бары 300—550 генә ат йөрде. Мәсәлән, Калинин исемендәге колхозның 132 баш аты бар. Бу колхоз алынган график буенча ашлык ташуда 80 баш ат йөртергә тиеш иде. Тикшереп карагач, колхозның эшкә яраклы 32 генә арбасы барлыгы беленде. Колхоз ашлык ташуга 25 аттан артык чыгара алмады. Шуның аркасында гына да бу колхоз ашлык ташуны 40 көн урнына 120 көннән артык ташыды. Арбалар җитешмәүнең бәләсе әнә шунда.

Алабуга районында мондый колхозларны дистәләп санарга мөмкин. Гомумән алганда район күләмендә 1.000 баштан артык эш атына арбалар җитешми. Әйтерсеңлә арба ясый белүче кеше юк инде. Ләкин, шунсы кызганыч, колхозларның эшенә зур тоткарлык ясый торган бу „вак-төяк“кә район оешмаларының да, колхоз җитәкчеләренең дә исләре китми.

Хәзер эш шуңарга кадәр барып җиткән ки, колхозларда булган арбаларны да төзәтүче юк, алар таралып яталар. „Победа“, „Правда“, „Ударник“, Калинин, Молотов исемендәге һәм башка күп кенә колхозларда арбалар колхозчыларның үз йортларында торалар. Ул арбаларның кайсысы көпчәксез, кайсыларының күчәрләре сынган, кайсысы тәртәсез, кабыксыз һ. б. Шулай итеп колхозларда арбалар саны һаман кими бара. Мәсәлән, „Победа“ колхозында яз көне 18 арба булган, дәүләткә ашлык тапшыру вакты килеп җиткәнче алар 14 кә калган.

Чаналар белән дә эш шулай начар тора. Колхозлар кыш керү белән чана юктан интегәләр. Менә кайбер колхозлар: „Новое Поле“ колхозында 48 баш эш атына 20 чана, Ильич исемендәге колхозда 19 баш атка 6 чана, „Пролетарий“ колхозында 60 атка 5, ә менә Армалы авылындагы „Красный Партизан“ колхозында 50 атка бары 8 чана бар.

Алабуга районында транспорт кирәк-яраклары җитәрлек булганда да кыш көннәрендә ат белән эшләп күп кенә доход алу мөмкинлекләре бар. Ләкин чаналар булмау аркасында „Новая Жизнь“, „Пролетария“, „Красный Партизан“ һәм башка күп кенә колхозлар атларны транспорт эшләренә файдалана алмыйлар, колхозга өстәмә доход китерә алмыйлар.

Ни өчен соң Алабуга районында арбалар һәм чаналар аз? Әллә аларны булдыру өчен бер төрле дә мөмкинлекләр юкмы? Киресенчә, Алабуга районында транспорт кирәкләрен булдыру өчен бөтен нәрсә бар. Алабуга үзенең тарантаслары, тимер ходлары һәм яхшы чаналар җитештерүе буенча элек-электән дан тота иде. Алабуга чаналары һәм тарантаслары Казан маркаларыннан алда торалар иде. Ул арбаларны һәм чаналарны эшләүче мастерлар әле дә Алабуга районы колхозларында. Арбалар һәм чаналар эшләү өчен кирәкле материаллар да җитәрлек. Тик инициатива гына җитешми.

Мастерларның иң күп урны Удаловка, Качка, Гари, Разживино авылларында. Бу авыллардагы колхозларда мастерскойлар ачып үз кирәкләрен генә түгел, башка колхозларны да арба һәм чаналар белән тәэмин итеп торырга мөмкин. Ә хәзергә исә бу колхозларда үзләре өчен дә арбалар, чаналар бик аз. Мәсәлән, Гари авылында 132 баш эш атына 32 арба, Качкада 55 атка 32 арба, Разживинода 48 атка 30 арба бар.

Мондый колхозларда транспорт кирәкләре эшли торган мастерскойлар ачу белән бер кем дә кызыксынмый. Бу мәсьәләдә бигрәк тә район советы башкарма комитетының промышленность бүлеге (мөдире иптәш Мостафин) һәм райплан эшлексезлек күрсәтәләр. Район советы башкарма комитетының промышленность бүлеге транспорт кирәкләре җитештерү эшен оештыру буенча гомумән бер нәрсә дә эшләми. Гүяки, арба һәм чаналарны әллә кайсы крайлардан кайтартырга кирәк булып чыга.

Алабугада берничә кустарь артельләре бар. Бу артельләрнең дә күбесе транспорт кирәкләре эшләп чыгара алырлык. Мәсәлән, Татлеспромсоюзның „Смычка“ артелендә (председателе иптәш Кошенков) чаналар, арбалар һәм көпчәкләр эшли торган мастерской бар. Ләкин бу мастерскойның эшләп чыгару мөмкинлегеннән тулысынча файдаланылмый. Арба-чаналар эшләп чыгару аз планлаштырыла һәм шул кечкенә план да тулысынча үтәлми. Мәсәлән, артель 1940 нчы елның 10 ае эчендә планда билгеләнгән 130 арба урнына бары 3 кенә арба, 320 чана урнына бары 72 генә чана эшләп чыгарган. Районда чаналар эшләүче оешмалар булмаудан файдаланып, артель председателе Кошенков колхозлар өчен авыр шартлар куеп договорлар төзүгә кадәр барып җиткән. Мәсәлән, „Красный Колос“ колхозы (председателе иптәш Волков) үз атлары белән артельнең чана ясау өчен кирәк булган материалларын ташып бирә. Хезмәт көннәре язып 4 колхозчы-мастерны артельдә эшләтә, ә артель моның өчен колхозга шул ук колхоз мастерлары эшләгән чаналарның һәрберсен 47 сумга сата. Шуның белән бергә артель бу колхоз мастерлары эшләгән 100 чананың 30 ын гына бу колхозга сатарга риза була.

Мондый хәлдән чыгу өчен мастерлары җитәрлек булган „Красный Колос“ колхозы арба һәм чана эшләүне үзендә оештыра ала. Икенчедән, район советы башкарма комитетының промышленность бүлеге „Смычка“ артеленең колхозлар алдына мондый авыр шартлар куюына чик куярга тиеш.

Алабуга районындагы башка кустарь артельләрендә дә арба-чана эшләүне оештырырга мөмкин. Ләкин үткән ел Татметаллпромсоюзның Алабугадагы „Ударник“ артеленә транспорт кирәкләре цехы ачу өчен 110 мең сум акча җибәрү билгеләнгәч, артельнең элекке председателе Гурьев „мәшәкатьләнүдән“ куркып бу акчаны алудан баш тарткан. Район оешмалары да бу фактка игътибар итмәгәннәр.

Район оешмаларының җитәкчеләренә арба, чаналар мәсьәләсенә „вак-төяк“ дип карауны ташларга вакыт. Мөһим эшләрне үтәгәндә „арба, чана юк“ дигән сылтауга киләчәктә юл куелмаска тиеш. 1941 нче елда барлык колхозларда һәр атка кимендә бер комплект төзек арба һәм бер чана булдырылырга тиеш. Моның өчен хәзердән үк районда арба-чаналар эшләп чыгаруны оештырырга кирәк. Барыннан да элек „Смычка“ артеленең арба-чаналар эшләп чыгару производствосын киңәйтергә, аның планын тулысынча үтәвенә ирешергә кирәк. Шуның белән бергә, „Ударник“ артелендә дә транспорт кирәкләре эшләп чыгаруны оештыруга керешергә вакыт. Эшне яхшы итеп оештырганда бу артельләр беренче класслы тимер ход арбалар һәм яхшы чаналарны күпләп эшләп чыгара алалар.

Соңгы вакытта райлесзаг көпчәк, чана табаннары өчен материаллар хәзерләү эшенә керешкән. Биредә көпчәк һәм чана табаннары эшләүгә тиешенчә игътибар биргәндә райлесзаг кимендә 500 пар чана табаны, 1.000 станнан артык көпчәк эшләп чыгара ала. Райлесзагтан чана табаннары, көпчәкләр сатып алу колхозларның үзләрендә арба-чаналар эшләүне киң җәелдерүгә зур мөмкинлекләр бирә.

Кыскасы, Алабуга районында арба-чаналар эшләүне районның үзе өчен генә түгел, бәлки элеккечә, моның белән Алабуга районының республика күләмендә дан тотарлык итеп оештырырга мөмкин.

Алабуганың ул даны кайтарылырга, яңадан тудырылырга тиеш.

К. Әхмеров.

Алабуга, „Кызыл Татарстан“ газетасының үз хәбәрчесе.

Терлекләрнең һәм йорт кошларының санын алуга хәзерлек

Терлекләрнең һәм йорт кошларының санын алу башлануга берничә көн генә калды. 1941 нче елның 1 нче январында иртән 8 сәгатьтә сан алучылар эшкә керешәчәкләр. Районнар барсы да диярлек 25 нче декабрьгә сан алучы кадрлар сайлап алуны һәм раслауны тәмам иттеләр инде. Бөтен республикада өлкән һәм кече сан алучылар итеп 3.703 кеше расланды. Контроль тикшерү буенча 513 бригадир расланды. Сан алуны үткәрү өчен бланк формалары һәм инструкцияләр барлык районнарга җибәрелде. Күп районнар инде сан алучыларга инструкцияләр бирүне тәмам иттеләр.

Авыл советларының бик зур күпчелегендә терлекләрнең санын алуга булышлык комиссияләре төзелде. Алар халык арасында массовый-аңлату эшләре алып баралар. Җирле матбугаттан һәм радиодан киң күләмдә файдаланыла.

Татарстан АССР Халык Хуҗалыгы Учеты идарәсе сан алуны үткәрүдә практик булышлык күрсәтү өчен районнарга 12 белгеч җибәрде.

Күп кенә район оешмалары хәзерлекне яхшы гына җәеп җибәрделәр. Шулардан Бөгелмә, Тәтеш, Чистай, Саба, Мөслим һәм Лаеш районнарын күрсәтергә мөмкин. ВКП(б) ның Бөгелмә райкомы партиянең түбәнге оешмалары аркылы сан алуга хәзерлекне киң күләмдә оештырды. Аерым алганда бу райкомның агитация һәм пропаганда бүлеге халык арасында аңлату эшләре үткәрүдә партиянең башлангыч оешмаларына зур булышлык күрсәтә. Бөгелмә һәм Чистай районнарында терлекләр санын алуга [illegible] Советлары депутатлары тартылды.

Лаеш, [illegible] районнарда эле [illegible] бар. Терлекләрне инвентарьлаштыру турында Наркомзем күрсәтмәләре [illegible] районнар җир бүлекләре барсы да [illegible]. Күп кенә район җир бүлекләре бу мәсьәлә буенча колхозларга язма директивалар бирү белән генә чикләнәләр. Шуның өстенә үз директиваларының үтәлүен тикшермиләр.

Юдино районында 25 нче декабрьгә карата терлекләрне инвентарьлаштыру эшенә бер колхозда да керешмәгән. Район җир бүлеге бу кимчелекне бетерү өчен бер нинди дә чара күрми.

Кайбер районнар бу яктан икенче бер чиккә ташланганнар. Алар терлекләрне инвентарьлаштыруны 1 нче декабрьгә карата үткәргәннәр (мәсәлән, Актаныш районы). Нәтиҗәдә, бер ай эчендә терлекләр санының үзгәрүен искә алу өчен бу районнарга сан алу алдыннан инвентарьлаштыруны икенче кат үткәрергә туры киләчәк.

Заинский район советы башкарма комитеты районда терлекләр санын алу турында район советының карарын чыгаруны кирәк дип тапмаган. Ул бары тик сан алу кадрларын раслау белән генә чикләнгән.

Терлекләрнең һәм йорт кошларының санын алуны уңышлы үткәрү өчен калган көннәрдә халык арасында массовый-аңлату эшен көчәйтергә, бу эшкә авыл интеллигенциясен һәм авыл активын тартырга, сан алучыларга инструкцияләр бирүне һәм аларны сан алу участкыларына беркетүне тәгалләргә, сан алу бланкларын һәм инструкцияләр тапшыруны тәгалләргә, колхозларда һәм дәүләт оешмаларында терлекләрне инвентарьлаштыруны 31 нче декабрьдән соңга калмыйча тәмам итәргә кирәк.

Һәрбер сан алучы, бригадир, булышлык комиссияләренең членнары һәм сан алуга катнашучылар барсы да [illegible] Татарстан АССР да терлекләрнең тулы [illegible] сан алуны тәэмин итәргә тиешләр.

А. Зайцев.

Татарстан АССР Халык Хуҗалыгы Учеты идарәсе начальнигы

Казан шәһәрендә һәм аңа карган бистәләрдә 1941 нче елның 1 нче январеннан алып 8 нче январена кадәр терлекләр санын алуга хәзерлек бара. Шәһәр советы башкарма комитеты һәм район советлары башкарма комитетлары янында сан алуга булышлык комиссияләре төзелде. Сан алуны үткәрү өчен работниклар, халык хуҗалыгы учеты идарәсенең район инспекторларына ярдәм күрсәтү өчен 300 техниклар билгеләнде.

Казан Шәһәр Советы Башкарма Комитеты барлык йорт идарәләренә терлекләр санын алган вакытта сан алучыларга һәм инспекторларга булышлык күрсәтү өчен җаваплы дежурныйлар билгеләп куярга тәкъдим итте.

Хәрби-тактик уеннар

Осоавиахим оешмалары мәктәпләрдә кышкы каникуллар вакытында хәрби-тактик уеннар һәм ярышлар оештыралар.

Казандагы барлык урта һәм тулы булмаган урта мәктәпләрдә укучылар катнашы белән шәһәр тирәсендә чаңгы походлары, химия, төз ату ярышлары һәм башкалар үткәрелә. Яшьләрне төз атуга өйрәтү өчен шәһәрнең кайбер кино-театрларында тирләр оештырылды. Киров районында ачылган тир аркылы да каникул көннәрендә мәктәп балаларына киң күләмдә хезмәт күрсәтеләчәк.

Ленин исемендәге 4 нче номерлы мәктәптә (Казан) елка бәйрәменә хәзерлек. Сулдан уңга—Шурмина, Гусенкова, Леонтьева, Архангельская һәм Савосина иптәшләр елканы бизәү өчен уенчыклар сайлыйлар.

В. Лаврентьев фотосы.

КЫШКЫ КАНИКУЛЛАРНЫ ҮТКӘРҮГӘ КАРАТА

Мәктәптә укыту-тәрбия эшенең яхшы сыйфатлы нәтиҗәләр бирүе күп төрле шартларга бәйләнгән. Укучыларның үзлекләреннән эш— хәзерлек алып барулары, көндәлек режимны тиешле дәрәҗәдә саклаулары, дөрес ял итүләре һәм сәламәтлекләрен ныгыта барулары—менә болар ул шартларның әһәмиятлеләреннән булып торалар.

Мәктәпләрнең гаять зур күпчелеге каникул вакытларында эшне яхшы оештыралар һәм, шуның белән, укучыларның дөрес ял итүләренә, ныгуларына ирешәләр. Ә кайбер мәктәпләр турында моны әйтеп булмый әле. Укытучылар, пионер һәм комсомол оешмалары эшне тиешле дәрәҗәдә оештырмаган урыннарда каникул вакты кирәкле нәтиҗәне бирми. Алай гына да түгел. Ял вакытының дөрес оештырылмавы, укучы балаларның үз ирекләренә ташланган булулары мәктәптә дисциплинасызлыкка, культуралы һәм дөрес ял итүдән читләшүгә, өлгерешнең түбәнәюенә алып килә.

Кышкы каникулны үткәрү мәсьәләсендә Казанның Бауман районы, Ленин исемендәге 4 нче номерлы урта мәктәбендә, Сталин районының 77 нче номерлы башлангыч һәм 80 нче номерлы урта мәктәпләрендә һәм башка күп мәктәпләрдә каникулга алдан ук хәзерлек алып барылды. Мәсәлән, 80 нче номерлы мәктәп махсус комиссия төзеде. Бу комиссия каникулны үткәрү планын төзеп, аны педагогия советында тикшерүгә куйды. План, шулай ук, пионер һәм комсомол оешмаларында да тикшерелеп, барлык укучыларга җиткерелде.

Каникул вактын үткәрү эшләрендә балаларның яшь аерымлыкларына нык игтибар бирергә, ял итү чараларын аларны ардырмаслык, талдырмаслык итеп билгеләргә кирәк. Укучылар өчен Казанның Пионерлар Йортында бөтен шәһәр күләмендә оештырыла торган елкада балаларның киң рәвештә катнашулары тәэмин ителергә тиеш.

Шуның белән бергә, каникул вакты мәктәптә оешкан рәвештә үтә дип кенә тынычланып калмаска, ата-аналар белән дә нык багланышта булырга, балаларның культуралы һәм дөрес ял итүләрен, сәламәтлекне ныгытуларын оештыруда ата-аналарның тулы ярдәмнәрен тәэмин итәргә кирәк.

М. Лотфи.

ҮЗӘК МУЗЕЙ ЮБИЛЕЕНДӘ

27 нче январьда Татарстанның Крайны Өйрәнү Үзәк музееның 45 еллыгына багышланган гыйлми конференция башланды. Тантаналы обстановкада үткән беренче утырышта музейнең гыйлми секретаре В. М. Дьяконовның доклады тыңланды. Музейнең 45 еллыгы турындагы бу доклад аудитория тарафыннан зур игтибар белән тыңланды.

Утырышта ТАССР ның атказанган сәнгать эшлеклесе, сәнгатне өйрәнү фәннәре кандидаты П. М. Дульский, профессор Воробьев, профессор Баранов иптәшләр музей турында истәлекләр белән чыктылар. Чувашстан АССР ның, Марий АССР ның Крайны Өйрәнү музейләре вәкилләре юбилярне котлап речь белән чыктылар.

Ахырда, музейнең эшен алга җибәрүдә күп хезмәт күрсәткән фәнни работниклардан, техник персональдан барлыгы 17 кеше Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты приказы буенча кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнде һәм 9 кешегә рәхмәт белдерелде.

Тантаналы утырыштан соң, конференциядә катнашучыларга концерт бирелде.

ТРАКТОРЛАРГА РЕМОНТ ЯСАУНЫҢ БАРЫШЫ ТУРЫНДА

Татарстан АССР Җир Эшләре Халык Комиссариаты сводкасы

1940 нчы елның 25 нче декабренә

(Көзге-кышкы ремонт планына карата процентларда)

МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш
Тымытык	100,0	Үзәк	16,7	Олы Карнак	7,6
Масаны	100,0	Актаи	16,4	Питрәч	7,6
Актаныш	55,3	Көкере Елга	15,4	Кармалы	6,9
Аксубай	47,2	Дөбъяз	15,1	Алексеевский	6,7
Нурлат	42,9	Кузнечиха	15,1	Әлхәмәт	6,2
Сарман	36,2	Кузайкино	14,8	Ищменко	5,6
Норлат	34,7	Буа	14,5	Әлки	5,5
Октябрь	34,4	Апас	14,5	Тат. Ятан	4,5
Столбище	31,7	Тат. Ходяш	14,3	Кошкино	4,2
Поповка	31,9	Сайман	13,8	Мин Чишмә	4,2
Солтан	30,4	Бәгелмә	13,8	Зур Полина	4,0
Мөрәле	30,2	Куйбышев	13,8	Балык Бистәсе	3,8
Тельман	29,2	Чистай	13,6	Мослим (Чистай)	3,8
Ис. Тимошкино	28,8	Т. Танак	13,6	Рождественский	3,2
Шегер	25,5	Саба	13,2	Исле Писмэн	3,0
Калинбаш	25,0	Билэр	13,2	Чурбулаш	2,3
Чаллы	23,7	Юртыш	12,5	Ромадан	2,1
Зирекле	21,3	Чуты	12,5	Чыбыклы	2,0
Эшче	20,9	Мамадыш	12,5	Ямаш	1,7
Телече	20,7	Такашев	12,0		
Каюкинский	20,6	Алабуга	11,5	Барлыгы:	14,5
Исәнбай	19,2	Майдан	11,5	Шул исәптән:	
Кызыл Чапчак	19,2	Тәтеш	10,9	Көньяк-көнчыгыш районнарда	17,6
Азнакай	19,0	Сокодка	10,9	Төньяк районнарда	15,4
Кукмара	19,0	Азин	10,6	Кама аръягы районнарда	14,3
Арча	18,7	Кичу	10,5	Көнбатыш районнарда	11,2
Базарлы Матак	18,6	Ленин	10,5	1940 нчы елның 20/XII на	13,3
Черемуховский	18,4	Тибәк	10,3	1939 нчы елның 25/XII на	21,7
Каргалы	18,3	Димитровский	10,0		
Әлмәт	18,2	Мәлки	10,0		
Буденный	17,9	Кадрык	9,5		
Тархан	16,9	Заински	9,4		
Балтач	16,9	Дрожжаное	9,1		
Балык	16,7	Кызыл Йолдыз	8,5		
Кызыл Юл	16,7	Макы	7,5		

Искәрмә: Калган МТС ларда ремонт ясалган тракторлар юк.

БӘЙРӘКӘДӘГЕ УКУ ӨЕНДӘ

Ютазы районының Бәйрәкә авылындагы уку өе өчен быел өч бүлмәле яңа бина салынды. Уку өе яхшы итеп җиһазланды.

Уку өенә 34 данә газета, 24 данә журнал алына. Аның китапханәсендә 3 меңнән артык китап бар. Бу китаплардан файдаланучыларның саны 700 нән арта.

Уку өе каршында [illegible] уку, әдәби китаплар уку, төрле темаларга беседалар, докладлар һәм лекцияләр системалы рәвештә үткәрелә. Шушы елның 11 ае эчендә уку өе активистлары [illegible] колхозчыларга 141 төрле доклад, лекция һәм беседалар үткәрелде. Уку өе янында драмтүгәрәк тә эшли. Драмтүгәрәк быел 14 спектакль һәм 17 тапкыр концерт бирде. Соңгы айларда драмтүгәрәк зур хәзерлек белән „Шәмсекамәр“, „Мактаулы заман“ һәм „Карлыгач“ пьесаларын куйды.

Шуның белән бергә уку өенең эшендә зур гына җитешсезлекләр дә бар әле. МОПР, Сугышчан Алласызлар Союзы һәм Осоавиахим оешмалары начар эшлиләр. Колхозчыларга хәрби белемнәрне өйрәтү оештырылмаган. Бу җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерергә кирәк.

М. Аптикашев.

Киномеханиклар хәзерләү

Районнардагы табышлы кинолларда эшләү өчен Саратов һәм Воронеждагы курсларда киномеханиклар хәзерләнә. Бу курслардан Татарстан өчен 50 дән артык киномеханик укып кайтачак.

1941 нче елда Татарстан авылларында кино челтәре тагын да киңәя. Шунлыктан янадан шактый күп кенә киномеханик кирәк булачак. Татарстан кинофикация идарәсе киномеханиклар хәзерләү өчен январь аенда Казанда 7 айлык курслар ача. Курслар аркылы Татарстан өчен 52, күрше республикалар һәм өлкәләр өчен 40 тан артык киномеханик хәзерләнәчәк. Курсларга керү өчен 7 еллык белем кирәк. Курсларга авыл җирләрендә торучылар гына кабул ителәләр. Укучылар стипендия белән тәэмин ителәчәкләр.

ВКП(б) НЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЫНЫҢ КИЧКЕ, МАРКСИЗМ-ЛЕНИНИЗМ УНИВЕРСИТЕТЫНДА

1 нче курста да, II нче курста да 31 нче декабрьгә билгеләнгән занятиеләр 29 нчы декабрьгә күчерелә. 1 нче курста һәр ике группа өчен, ВКП(б) тарихы буенча, „Большевикларның [illegible] марксистик партия булып оешулары“ дигән темада лекция укылачак. Лекцияне [illegible] доценты А. П. [illegible] укый. Диалектик материализм буенча лекция темасы: „Марксистик диалектиканың [illegible]“. [illegible]

„Ял көне бүлеге“ндә (элекке Ял Көне университеты) чираттагы занятиеләр якшәмбе көн 5 нче январьда Авыл Хуҗалыгы институты бинасында булачак.

ВКП(б) тарихы факультетында (институтның актовый залында) „Тарихи материализмның төп билгеләре“ дигән темада лекция укылачак.

Философия факультетында (аудитория №38) „XVIII һәм XIX нчы гасырларда Россиядә материалистик философиянең үсеше“ дигән темада лекция булачак.

Гомуми тарих факультетында (аудитория №39) укылачак лекциянең темасы: „XI нче гасыр ахрыннан башлап Көнбатыш Европаның экономик үсеше, шәһәрләр килеп чыгу, тәре походлары. X—XV нче гасырларда Германия һәм Италия“.

Гомуми әдәбият факультетында (аудитория №34) түбәндәге темада лекция укылачак: „Англиядә ренессанс. Шекспир эпохасы театры. Шекспир иҗадының беренче чоры“.

„Ял көне бүлеге“нең университетның кичке бүлегенә күчәргә теләүче барлык тыңлаучыларыннан, үзләренең күчүләрен киләсе занятиегә кадәр рәсмиләштерүләрен һәм 29 нчы декабрьдән кичке бүлектә укырга керешүләрен үтенәбез.

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитетының кичке, Марксизм-Ленинизм университетының канцеляриясе Авыл Хуҗалыгы институты бинасында (Карл Маркс урамы, 65. Телефон 13—75. 3 һәм 6 нчы трамвайлар бара). Занятиеләр 10 нан 7 гә кадәр.

Дирекция.

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответственный редактор
Х. АБДРАХМАНОВ.

ФӘННИ ТЕМАЛАРГА

Ми һәм аны өйрәнү

Ми—фикерләү органы, кешенең психикасындагы нечкә һәм катлаулы процессларның материаль нигезе. Аны өйрәнү фәннең үсүе өчен, бигрәк тә теоретик һәм практик медицина өчен гаять әһәмиятле.

Моннан 15 ел элек, хөкүмәт карары белән, Москвада мине өйрәнү өчен махсус лаборатория төзелгән иде. Хәзер ул Ми институты итеп оештырылды. Институтта бик күп галимнәр, белгечләр эшли.

Институтның музее бар. Анда гаять бай коллекцияләр җыелган.

Алар тереклек ияләренең нерв системасы ничек үсүне күрсәтәләр. Баш мие кабыгының ничек үсүен күрсәтә торган экспонатлар аеруча күп.

Шулай ук музейдә кеше миенең яралгы вактыннан алып бала туганчыга кадәр, ә аннан соң олы кеше булганчыга кадәр ничек үсүен күрсәтә торган шактый күп коллекция бар. Экспонатлар нерв тукымасының бик кечкенә генә кантардан торабара башта мигә бик аз гына охшый торган формага, ә соңыннан үзенең төзелеше буенча торган саен күбрәк дәрәҗәдә олы кешенең миенә якынлаша торган формага керүен күрсәтәләр. Бала ана карнында булуның беренче айларында минең өске ягы шома була, соңыннан анда чак кына сизелерлек сызыклар ясала башлый. Болар—ускәч булачак образларның урыннары. Ә беркадәр вакыт үткәч буразналар үзләре дә килеп чыгалар. Бала туган вакытта аның мие тышкы яктан олы кешенең миеннән күләме белән генә аерылып тора.

Минем төзелешендә төп эш бер—нәрсә һәм бер кешене икенче кешедән нәрсә аерып тора дигән мәсьәлә галимнәрне күптән кызыксындыра инде. Баштарак, кешеләр бер-берләреннән үзләренең миләренең авырлык үлчәве белән аерылалар дип уйлыйлар иде. Ләкин минең авырлык үлчәвенең хәл иткеч нәрсә түгеллеге беленде. Ул гәүдәнең үлчәвенә, кешенең буена һәм күп кенә башка нәрсәләргә бәйләнгән. Мәсәлән, бер җүләрнең мие 2.000 грамм, ә зур бер язучының мие 1.017 грамм булып чыккан. Кеше миенең уртача авырлыгы—1.400 грамм, ә кайбер хәйваннарның мие, мәсәлән, фил мие 4.000 граммга, кит мие 7.000 граммга кадәр җитә.

Аннан соң мидәге буразналар кешенең ни дәрәҗәдә талантлы икәнлеген күрсәтәләр дигән фикер дә бар иде. Дөрес, мидәге буразналарның тышкы күренеше минең үзенчәлекләрен билгеләгәндә бик әһәмиятле. Ләкин бер минең икенче мидән аермасы турындагы мәсьәләне хәл иткәндә бары тик төрле билгеләрнең җыелмасы гына һәм бигрәк тә минең нечкә микроскопик төзелешен, аның химик составының үзенчәлекләрен һәм аның кан белән ничек тәэмин ителүен белү генә нигез була ала.

Тикшерүченең микроскопы астына килеп кергәнгә кадәр ми институтта махсус рәвештә эшкәртелә. Төрле фиксацияләрдән үткәннән соң мигә тышкы яктан парафин коялар һәм шул хәлендә ми озак вакытлар саклана ала. Мине аннан соңгы эшкәртү түбәндәгечә бара: парафин эчендә калдырылган мине микротома дип аталган махсус аппаратка каретка буйлап йөреп, мине папирос кәгазе кебек, 25 микрон калынлыктагы бик юка катлауларга турый. Бер сантиметр калынлыктагы ми кисәгеннән шушындый кисәкләр 400 данә чыга. Бөтен ми 15.000 чамасы кисәккә турала. Бу кисәкләрне пыялаларга ябыштыралар, аларга номерлар сугалар һәм махсус буяулар белән буейлар. Хәзер инде алар тикшерү өчен хәзерләнеп беткән булалар.

Бу кисәкне микроскоп аркылы караганда тәҗрибәсез кеше бары тик үзара буталып беткән вак күзәнәкләрне генә күрә ала. Белгеч исә микроскоп аркылы карап минең үзенә бер төрле төзелешен таба.

XX нче йөз башында ми турындагы фән бик алга китте. Күзәнәкләр төзелешен өйрәнү нигезендә галимнәр зур ми кабыгының төзелеше бер генә төрле түгеллекне һәм анда төрлечә төзелгән урыннар барлыкны исбат иттеләр. Мондый урыннар „кырлар“ дип аталдылар. Бродман аларны 50 ләп санаган. О. Фогт исә 200 ләп „кыр“ бар дигән фикергә килде.

Институтта зур ми кабыгының күзәнәк төзелешен өйрәнгән вакытта, ми „кырлары“ның урнашуы, бу „кырлар“ алып тора торган мәйдан, күзәнәкләрнең нечкә төзелеше ягыннан һәрбер минең үзенә аерым үзенчәлекләре бар дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Шул нигездә институтта берничә күренекле кешеләрнең миләрен тикшерү эшләре башланды.

Алынган нәтиҗәләр теоретик яктан бик әһәмиятлеләр, ләкин клиницист врачлар өчен һәм ми хирургиясе өчен дә аларның зур практик әһәмияте бар.

Әгәр дә олы кеше миенең тарихи үсеше өйрәнелмәсә аның ми кабыгының нечкә төзелешен аңлап булмас иде. Бу өйрәнү ике юл белән алып барыла: онтогенез юл, ягъни бала ана карнында чакта аның баш мие кабыгы ясалу моментыннан алып бала туган вакытка кадәр бу кабыкның ничек үсүе тикшерелә. Икенчесе филогенез юл, ягъни тереклек ияләрендә баш мие кабыгы төзелешенең торган саен катлаулана баруы өйрәнелә.

Онтогенез буенча институтның эшләре мидәге аерым „кырлар“ның үсеше бер үк вакытта булмаганлыкны күрсәтәләр. Бала туган вакытта ук инде аның ми кабыгында олы кеше мие төзелешенең барлык төп билгеләре була. Ләкин бу ми тагын да үсүдә дәвам итә. Бала ике яшенә җиткәндә ми кабыгында зур гына үзгәрешләр була.

Мидә була торган төрле авырулар вактында ми тукымасының төзелеше бозыла. Институтта үзәк нерв системасының кайбер авырулары вактында ми кабыгы төзелешендә була торган үзгәрешләрне өйрәнәләр.

Минең катлаулы эшен аңлау өчен аның төзелешен өйрәнү генә җитми. Шунлыктан институтта ми кабыгы төзелешенә бик нык бәйләп минең физиологик эшен өйрәнәләр. Маглүм ки, тере тукымада электрик күренешләр була. Институтның электро-физиология бүлегендә әнә шул күренешләрне өйрәнәләр.

Шулай ук институтта зур ми кабыгы төзелешенең биохимик үзенчәлекләре дә өйрәнелә.

Институтның фәнни сотрудниклары бик күп әсәрләр чыгардылар. Шулай ук кешенең һәм хәйваннарның баш мие атласы чыгарылды. Бу атлас врачлар өчен, физиологлар һәм биологлар өчен, медицина вузлары өчен ярдәмче материал булып хезмәт итә.

Н. Преображенская.

Ми институтының фәнни секретаре.

Татар Дәүләт Опера театры
Татар Дәүләт Академия театры бинасында
3 нче январьда
ЧИО-ЧИО-САН

Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры
Бүген, 30 һәм 31 нче декабрьдә
Г. Камал әсәре
БӘХЕТСЕЗ ЕГЕТ
Билетлар сатыла.

КУЛЬТУРА САРАЕ
Бүген
ГАЛИЯБАНУ
Билетлар сатыла.

Зур Драма Театры
Бүген, 30 һәм 31 нче декабрьдә
АНДЖЕЛО

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
ЧЕГЕН
АМИНЫҢ

БҮГЕН КИНОЛАРДА:
„Электро“ — ЮЛЛАРДА
„Унион“ — КАЙТУ
„Кызыл Йолдыз“ — СОҢГЫ ТӨН
„Пионер“ — Бишенче океан
„Колхозник“ — КАЙТУ
„Чаткы“ — ЮЛЛАРДА
„Рот-Фронт“ — ТОРМЫШНЫҢ БӘЯСЕ
„Культура сарае“ — ЦИРК

КАЗАНДАГЫ АПТЕКАЛАРГА
БОРЖОМ
„ЕССЕНТУКИ“
„Лютеогландол“
„Профилантикум“

ТАТАРКОМЗЕМ ЯНЫНДАГЫ „ВОДОСТРОЙ“
ДОГОВОРЛАР ТӨЗҮ ЭШЕНӘ КЕРЕШТЕ

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Каз., Матбугат Йорты. ТЕЛЕФОННАР: пропаганда бүлеге һәм экономик бүлек 18—22, секретариат 5—86, партия бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, төнге редакция 3—75, типография 33—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.
ПФ 4093 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ. 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 5582.